Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 9 (1425) 10 март 2023 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:
madani_zhomga madanizhomga
madani_zhomga

8

«Нәҗибә дә, мин дә театрның ни икәнен күз алдына да китерә алмыйбыз, чөнки татар театрын күргәнебез юк иде».

12

Бөтен татарның борчыган мәсьәләләр Екатеринбург каласындагы милләттәшләребез өчен дә көн үзәгендә.

14

Рәссам-монументалист, график Илнур Сиражиев сәләтле яшьләребезнең башкалага китүенә, аларны монда алып калу өчен чара күрелмәвенә борчыла.

Юныс ага варислары бүген Дан китерә татар ашларына!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Казан һәм Татарстан митрополиты Кирилл Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановка XX гасырның 20 нче елларында язылган шәмаил бүләк итте.

- Татарстан Сынлы сәнгать музееның «Хәзинә» милли сәнгать галереясында «Казан авангарды. Икенче дулкын» циклыннан күренекле татар рәссамы Рөстәм Килдебәковның эшләре тәкъдим ителде.

- Казан дәүләт мәдәният институтында узган «Сандугач» X халыкара конкурсында «Идел» татар фольклор ансамбле III дәрәҗә лауреат булды.

- Татар китабы йортында язучылар Кави Нәҗми һәм Сәрвәр Әдһәмованың шәхси хатлары буенча «Сүнмәс яктылык» дип аталган эпистоляр спектакль күрсәтелде.

- К.Тинчурин театрында яшь режиссерлар өчен курслар башланды.

- Санкт-Петербургтагы Россия этнография музеенда «Иман һәм игелек юлы: Россия мөселман халыкларының сәнгати традицияләре» күргәзмәсе ачылды.

- Әлмәт театры актеры Динар Хөснетдиновка Татарстанның атказанган артисты исеме бирелде.

- Бөтендөнья татар яшьләре форумы Сочи шәһәрендә Көньяк федераль округының татар яшьләр оешмалары җитәкчеләре һәм активы өчен «Акыл фабрикасы» белем бирү мәктәбен уздырды.

- «Бәхетле балачак» иҗади үсешкә ярдәм үзәге» оешмасы, Чаллы шәһәренең Муллануp Вахитов исемендәге 2 нче гимназиясе «Кызыл төлке» ачык милли татар сәнгате республика конкурс-фестивале оештыра.

- 12 мартта Ульяновскиның Татар мәдәнияте үзәгендә Буа дәүләт драма театры мәгърифәтче Нургали Хәсәнов тормышына багышланган «Дәрвиш» спектаклен тәкъдим итә.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Нәфисә АКЧУРИНА, Мәрьям Солтанова-Акчурина исемендәге зыялылар клубы җитәкчесе:

«Минем өчен «Идегәй» дастаны – кемнеңдер кемнедер сатуы түгел, ул дәвер ханнарының, батырларының, сугышчыларының, сатлыкҗаннарының, чәчәннәренең, колларының җыелма образлары, аларның сугышлары, җиңүләре, җиңелүләре, көнкүрешләре. Халкыбызның тел байлыгы, тарихы, дипломатиясе».

СЫНАМЫШЛАР

Искечә 1 мартта (хәзер 14 мартта) аяз булса, бөтен яз аяз була● Әгәр 14 мартта тәрәзәләргә боз катса, бу елны кыяр уңа● 14 мартта көн җилле булса, бөтен җәй җилле була● 14 мартта урамда су күренсә, язгы ташуда су күп килә● 14 мартта җылы булып, тамчы тамса, кар тиз китә, бөтен җәй җылы була.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **6 сәгать 14 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 35 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **11 сәгать 21 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **33 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **17 мартта 11 сәгать 54 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

10 март – актёр, режиссёр, Татарстанның халык артисты Хәким Йосыф улы Сәлимҗановның тууына 120 ел (1903–1981).

11 март – шагыйрь, прозаик, драматург, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әхмәт Әхмәтсафа улы Фәйзинең (Фәйзуллин) тууына 120 ел (1903–1958).

12 март – рәссам Илгиз Мәснәви улы Хановка 75 яшь (1948).

13 март – мөгаллим, язучы Мөхәммәт-Кәбир Әхмәткәрим улы Туйкин тууына 145 ел (1878–1938).

15 март – язучы, мәгърифәтче, мөгаллим Закир Һадиның тууына 160 ел (1863–1933).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Мартның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 15 март.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(7-15 март)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген шәгъбән аеның 18 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Габделхак МИНГАРИПОВ

Суша – «Коры елга»мы?

Балык Бистәсе – Котлы Бөкәш юлының Суша елгасы аша салынган тимер-бетон күпер янәшәсенә күрсәткеч такта урнаштырылган. Аңа: «р.Суша – Коры елга», дип язылган. «Суша» сүзе ни сәбәпле «Коры елга» дип тәрҗемә ителәдер, мондый гамәл өчен нинди «галим»нәргә акча түләнгән – аңлавы бик читен. Һәрхәлдә, «суша» сүзенең татарчага «коры җир» дип тәрҗемә ителүен Мәннән анасы да чамалый югыйсә. Нишләп районыбызны иңләп, йөзләгән чишмәләрдән алган сулары Чулманга тапшырган Шомбыт, Әшнәк, Бәтке, Урай инеш-елгалары белән кардәш, 32 чакрым озынлыктагы Сушаны шулай Коры елга дип мыскыл иткәннәр соң? Безнең узган гомерләргә шаһит, бертугандай якын инешебез бит ул! Каз көтү сылтавы белән көннәр буе коенган булып, суыннан чыкмыйча яткан бала чакларыбызны ничек онытасың! Су тегермәне өчен буылган буа суы кышка җибәрелмичә калып, җәелеп туңган бозында «шара таяк» уйнаулар яки апрельдә боз киткән мизгелләрне хозур кылулар ничек онытылсын, ди! Шушындый елга-инешне «Коры елга» дип атауны мыскыл итү дип бәяләмичә мөмкин түгел!

Күки авылыннан көнбатышка 4 чакрым ераклыкта, урман эчендәге мул сулы гаҗәеп табигатьле чишмәдән башлангыч алып, Чулманга койганчы үз юлында сулары энәргә яраклы булган берничә дистә чишмәдән туенып, төбәгебез халкын тормыш-көнкүрешкә зарур суы белән кинәндергән әлеге инешебезнең су алу (җыйнау) мәйданы гына да 313 кв.км ны тәшкил итә. Суша буена урнашкан Күкинең дә тирә-юньгә моң таратып аккан дистәләгән чишмәсе бар. Балтачның Күгәрченгә таба чыккандагы чишмәсе үзе генә дә ни тора! Ә алар белән безнең ике арадагы Алатай, Мүләкәй чишмәләрен әйткән дә юк – кыйбла вә шәрыкка карап аккан шарлавыклы, мул сулы чишмә алар. Авылыбыз уртасында Сушага сул яктан 7 чишмәнең суы белән туенучы Кече су (Чәй суы) килеп кушыла. Күгәрчен кешесе бүген авылдан төньякта 4 чакрым ераклыкта урнашкан шушы чишмәләрнең торба аша килгән суын куллана. Олы юлдагы күпергә терәлеп диярлек, Сушага уңъяк кушылдык булараk, Тегермәнлекләрдән килүче Сула елгасы (аны борынгыдан Артсу дип йөрткәннәр) кушыла. Монысының да Сула дигән атамасына янә бер сәер, аңлашылмас муенчак – Сола дигән тәрҗемә уйлап тапканнар һәм Күгәрченгә кергәндәге күпер янәшәсенә ике телдә «р.Сула – Сола елгасы» дигән такта урнаштырганнар. Кем әйтмешли, гаҗәп. Русларга аңлашылмаса да, сула сүзен татарча ике мәгънәдә аңлап була. Ә менә «сола» – сүзлекләрдә дә андый сүз тапмадым. Сула һәм сола сүзләренең тәңгәллеген килгәндә, гәп куертып та утырасы түгел. Вакытлы матбугатта, радио-телевидение тапшыруларында оешма, предприятие, учреждениеләрнең әлмә такталарын, урам исемнәрен, төрле атамаларны Татарстандагы ике дәүләт телендә язмау (яки хата белән язу) турындагы өч дистә елга якын тәнкыйтьләүләргә җавап итеп эшләнгән эшме бу? Ничек кенә булмасын, мөгез чыгаруга охшаш гамәлләр бу. Тарихка күз салмый гына, топонимика фәнен санга сукмыйча аясә җирле халык фикерен белмичә, өйрәнмичә кылынган адым.

Ә тарихка күз салсак, анда хәлләр болайрак. Иң башлап, халкыбыз телендәге риваятькә нигезләнгән фикергә игътибар юнәлтик. Ул фикерне 1913 елда авылыбызның гыйлем иясе, тарихтан нык хәбәрдар булган аксакалыбыз Усман Шәмсетдине әйткән: «Бу тирәләргә килеп чыккан ерак бабаларыбыз шушы су буендагы чишмә өстенә (Күгәрчен кешесе Кер чайкый торган чишмә дип атап йөрткән чишмә – **Г.М.**) килеп утыруны муафыйк дип таба. Ул заман әле агымсуның исеме булмаган. Суны Шушы су дип атап йөрткәннәр... Гасырлар үтү белән, халык телендә бу инешнең исеме Шушы дан «Шошы»га, аннары «Чошы»га үзгәрә, ахыр чиктә «Суша»га әйләнә». Риваятьтәгеләрне раслау ниятеннән документларга күз төшерик. Мәскәүдәге Россия Дәүләт Борынгы Актлар архивында (РГАДА) Күгәрчен авылы турында беренче телгә алыну 1561/1566 елларга туры килә (ә без Күгәрченгә нигез салыну елын галим-археолог Равил Фәхретдинов фатихасы белән ике гасырга элгәрәк булган 1367 ел дип йөртәбез). Архивтагы «Книги Казанского уезда поместных земель детей боярских, Казанских старых жильцов, письма и меры Дмитрия Андреева сына Кикина с товарищи лета 7070 (1561/1566)» дигән кулъязма китапта Суша елгасы Шуша дип телгә алына (бу якташыбыз, язучы һәм тарихчы Нурулла Гариф мәгълүматлары). Ә менә «XVIII гасыр ахырында Казан губернасы Лаеш өязендә җирләрне үлчәү, чикләрне билгеләү турындагы икътисади искәрмәләр»дә Күгәрчен авылы турында «1795 ел. Авылда 70 йорт. 228 ир-ат һәм 256 хатын-кыз яши. Күгәрчен авылында өч тегермән. Авыл үзе Сушаның сул ягында...» дигән мәгълүмат бар. И.А Износковның 1895 елда Казанда басылган «Список населенных мест Казанской губернии с кратким их описанием. Вып.2. Лаишевский уезд» исемле китабында да елга Суша исеме белән телгә алына. Ә «бөек тәрҗемәчеләр» тәкрарлавына таянсаң, Коры елгада өч су тегермәне була аламыни?! Бездә хәтта җил тегермәннәре дә гомумән булмаган бит. Авылга дәүләт челтәреннән электр тоташтырылганнан соң гына (1967 ел), соңгы су тегермәненең дә кирәге калмый, ә буа буып су күтәртүне әле 1975 елга чаклы дәвам иттеләр. Гәрчә атамалар тәрҗемә ителергә тиеш түгел. Суша да, Сула да татарга да, русларга да әйтү өчен берничә кыенлык тудырмый. Шулай булгач, нигә дип мөгез чыгарырга да, ник дип кычытмаган җирне кашып маташырга?! Болардан башка да безнең район биләмәсендәге исем-атамаларда гаҗәпләнерлекләре байтак. Мисалга, Уракчы авылы исеме. Балык Бистәсе – Котлы Бөкәш трассасы буенча барганда күрсәткеч: Уракча. Ике телдә түгел. Югыйсә, авылның русча исеме – Урахча, татарчасы – Уракчы дип күрсәтелергә тиеш. Таянырлык, нигезләнерлек норматив-хокукый актлар бар. Әйтик, 2013 елның 18 октябрендә Президент Р.Миңнеханов имзалаган 81-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Татарстан Юстиция министрлыгының 2018 елның 23 гыйнварындагы 8-од номерлы Боерыгы. Әлеге документларда: Котлы Бөкәш сүзендә сызыкча (дефис) юк, Бөкәш дигәндә ө урынына ү түгел. Балыклы Чүкәйдә дә сызыкча юк. Аларда Зәңгәркүл дигән язылыш бирелгән, ә юлдагы күрсәткечтә Зәңгәр Күл тора, авыл җирлеге документларында да шулай. Мәшләк тә Олы түгел, ә Зур Мәшләк. Троицкий Урайда сызыкча юк, Трой-Урай да түгел. Шетнево-Тулуш авылы – татарча Югары Ырга. Тик бу закон көчендәге документларда да гаҗәпләнерлек пунктлар шактый. Без гомер буе атап йөрткән Шомбыт авылы Шомбыт түгел икән, ә бәлки Шумбут. Шомырбаш урынына районның авылы Законда һәм Боерыкта Шомарбаш дип атала. Шул Шомарбашны гына алыйк. Тарихчыбыз Н.Гариф билгеләп үткәнчә («Тарихи сәхифәләр ачылганда» китабы, Казан, 2008 ел, 32 бит), авыл, Шомыртлы елгасы башында урнашкан. Шуңа күрә ул һичьюгында Шомыртбаш дип аталырга хаклы. Ә монда: Шомарбаш. Мәзәккә әйләндерсәк: ул баш нилектән шомарган да, кем шомарткан? Кемнәр уйлап тапкан? Дөньяга чыкмыйча гына, төбәк тарихларына, гореф-гадәтләренә күз йомып, дүрт яклы диварда утырып тәрҗемә итүчеләрнең эшедер инде. Гаҗәп. Исемнәрнең ярты өлеше татарча, яртысы русча. Алай була алмый! Кара инде: Околоток – Яңасала. Нәрсә бу? Сүзлектә: околоток – тирә-як, тирә-юнь диелгән. Ул ямьсез яңгырашлы околоток ник өстәлгән Яңа Салага? Авылның исеме болай да менә дигән яңгырашлы. Законда Олы Кульга дип бирелгән Большая Кульга. Н.Гариф билгеләп үткәнчә, билгесез исемдәге күл буена урнашканлыктан, Олы Күл исеме җисеменә турырак килмиме? Ә менә күгәрченлеләр үзләренең ызандаш күршеләрен борын-борыннан Олы көл, Кече көл дип йөрткәннәр. Мин кайсының дөреслеккә туры килүен белмим: күлме яисә көлме? Яки Мельничный Починокны ничек биргәннәрен кара инде: Мельничный Пүчинкәсе. Татарча андый исем буламы? Почынокны Пүчинкә дию аңлашыла: башка чыккан, аерылып чыккан авылны аңлатадыр, Мельничныйны Тегермәнле яки Тегермән Пүчинкәсе дип атасаң, мантыйкка туры килер төсле. Зәңгәркүл, Яңасала нишләп, нинди орфографик кагыйдә буенча кушылып язылырга тиеш икән? Алай булгач, ни өчен Иске Арыш, Олы Әшнәк, Кече Кадрәк, Түбән Тегермәнлекләрне дә кушып язмыйбыз? Шетнев-Чирмешәнне ничек аңларга? Бәлки (Н.Гариф искәрмәсендәгечә) Шетнәү дип атау урынлыдыр. Мондый исемнәр саф татарча түгел бит, ярымтатарча, ярымурысча. Яңгырашлары да сәер. Татарстаныбызның бер гасырлык юбилеен билгеләп тә, әлеге атамаларны тәртипкә китерү юнәлешендә берни кылмыйча, ләм-мим, карусыз гына туган төбәгебездәге исем-атамаларны шулай ярты-порты бозып кулланып гомер кичерүебезне кайчанга кадәр дәвам итәрбез икән? Гәрчә без атамаларны, торак пунктларның, табигый урыннарның исемнәрен нәкъ шул Закондагыча, Боерыктагыча әйтүгә, язуга һәм куллануга кучәргә тиешбез бит. Шулай булмаса, районыбыз белән Законны бозучылар исемлегенә керүебез мөмкин. Районыбызның хакимият органнары, һәрбер авыл җирлеге дә, оешма һәм учреждениеләр дә үз документларында (бланкларында да!), шул исәптән районыбыз газетасы «Авыл офыклары» да, ике теллелекне саклап, исем-атамаларны шул норматив хокукый актлардагыча язарга тиеш. Ошыйммы алар безгә, юкмы – башка юл юк.

Күгәрчен авылы,
Балык Бистәсе районы.

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Киләчәкнең чалыш чалымнары

Хактыр ки, киләчәкне һәркем матур итеп күрергә тели. Әмма аның нинди булачагын беркем дә төгәл генә әйтә алмый, гәрчә тәкъдирдә язылганны гамәлгә ашыруда адәми затка иҗтиһат итү иреге бирелсә дә. Әйе, бер яктан, акыл иясе буларак, аннан моның өчен бары тик кайда, кайчан һәм нәрсә эшләргә кирәклеген аңлап гамәл кылу гына таләп ителә кебек. Ә чынбарлыкта бар нәрсә дә үзара тыгыз бәйләнештә һәм ниятләгәннәреңне син дигәнчә генә барып чыкмаска да мөмкин, чөнки күп әйбер конкрет вәзгыятьтән һәм аңа бәйлелектән дә тора. Әлбәттә, мондый хәл, тулысынча, уртак киләчәккә дә кагыла. Шуңа күрә, кешелекнең гомуми киләчәген гөман кылганда да, бүгенге конкрет вәзгыять вә тенденцияләрдән тыш, дөньяда хөкем сөргән караш вә каршылыкларны да исәпкә алып һәм ил-көндә бара торган геосәяси вә метасәяси процесслардан чыгып фикер йөртергә туры килә.

Әйтелгәннәрдән чыгып караганда, соңгы вакытларда ишарәле вакыйгалар күп булды. Алар рәтенә күптән түгел (17-19 февраль) иминлек буенча үткән Мюнхен конференциясен, БМО Генераль Ассамблеясенең 22-23 февральдә узган гадәттән тыш махсус сессиясен, АКШ дәүләт сәркатибе Энтони Блинкенның ай ахырында Үзәк Азия илләренә кылган сәфәрен, «зур егермелек» (G20) илләре тышкы эшләр министрларының 2 мартта Яңа Дәһлидә үткән саммитын, Украинадагы вакыйгалар тирәсендә соңгы вакытларда күзәтелә торган кайбер тенденцияләрне, шулай ук күп кенә башка вакыйгаларны да кертергә була. Узган язмаларда беренче икесенә шактый ук тәфсилле тукталган идек. Бүген исә игътибарны вакыйгаларның калганнарына да юнәлтергә туры килер. АКШ эмиссары Э.Блинкенның Үзәк Азия илләренә сәфәрен, кыска гына итеп, Кытай белән Россияне бу төбәктән кысрыклап чыгару стратегиясен гамәлгә ашыру, дип тә бәяләргә булыр иде. Үзенең әлеге вояжын ул Казахстаннан башлаган. Астана исә АКШ белән мөнәсәбәтләр бүген стратегик хезмәттәшлек рәвеше алуы, бу ил иң эре инвесторларның берсенә әверелүе турында белдергән. Биредә «С5+1» төркеме илләренең (Казахстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан) тышкы эшләр министрлары да катнашкан утырышында сүз икътисад, энергетика, сәүдә, иминлек кебек һ.б. өлкәләрдә элемтәләрне киңәйтү, ә терроризм, экстремизм ише күренешләр белән көрәшне көчәйтү турында барган. Үзбәкстанда исә төп игътибар инглиз телен укытуны яхшыртуга бирелгән.

G20 министрларының ябык режимда үткән утырышында Европа илләре үзәк мәсьәлә итеп Украина темасын куярга теләсәләр дә, оештыручы як (Һиндстан) моңа каршы килгән. Украинадан вәкил анда чакырылмаган һәм бу илгә хәтта онлайн режимында чыгыш ясау мөмкинлеге дә бирелмәгән. Шуңа да карамастан, ул тема күпләр чыгышында үзәктә булган. Россия һәм Кытай «Төньяк агымнары» буенча тикшерүләр үткәрү проблемасын да күтәргән. С.Лавров исә Көнбатышны дөньяда икътисади һәм азык-төлек кризислары китереп чыгаруда гаепне Россиягә аударып калдыруда гаепләгән. Нәтиҗәдә, йомгаклау документының уртак текстын бу ике ил кире каккан, ә утырыш рәис ил әзерләгән резюме белән генә төгәлләнгән. Анда исә күпчелек илләрнең Украинада башланган һәм дөнья икътисадына тискәре йогынты ясаган конфликтны кискен гаепләп чыгулары турында да әйтелгән. Шуны да искәртеп үтик, бу утырыш G20 лидерларының быел сентябрьдә узачак саммиты алдыннан үткәрелгән төп әзерлек чарасы да булып тора. Ә җәйге чорда Украинадагы вәзгыять җитди үзгәрешләр кичерергә мөмкин. Шуңа күрә, аңлашыла булыр, G20 лидерларының сентябрь саммитында Украина буенча уртак фикергә килә алу-алмаулары геосәяси әһәмияткә дә ия. Мәгәр, кешелек өчен глобаль фаҗигане булдырмый калу да күп яктан шуңа бәйле булачак.

Күренә ки, яңа дөньяви тәртип урнаштыру турында сүз йөртергә әле иртәрәк. Офыкта әлегә аның чалыш чалымнары гына шәйләнә. Чыннан да, глобаль дәрәҗәдәге каршы тору идеологик яктан «автократия-демократия» көрәше шәкелендә барса, геосәяси планда инде ул «берполярлы дөньямы, күппоярлы яңа дөньяви тәртипме» рәвешендәге дилеммага гына кайтып кала. Инде шул нигездә капма-каршы ике глобаль коалиция дә формалашып килә. Алар үзләренең хәрби сәнәгать комплексларын да сугыш режимына күчерергә җыенуларын исәпкә алсак, якларның инде глобаль каршылыкны да яу кырында (ягъни, әүвәлгечә үк, гео-сәяси ысуллар белән) хәл итәргә омтылышларын аңларбыз. Әмма кешелек дөньясының төп проблемасы бүген рухият өлкәсендә ята һәм аның геосәяси чишелеше була да алмый. Юкса, бүгенге технологик мөмкинлекләрне дә исәпкә алганда, андый ахмаклык инсаниятне фәкать глобаль фаҗигагә генә китерергә мөмкин. Ә рухи яшәеш проблемалары бары тик метасәясәт (илаһият кануннары буенча яшәргә көчү сәясәте) югарылыгында гына хәл ителә ала.

Фоат УРАЗАЙ.

«Татар никахы» нинди булырга тиеш?

Никах мәҗлесен дини һәм милли шартларга туры китереп уздыру нечкәлекләрен билгеләү, «татар никахы» дигән төшенчәгә ачыклык кертү максатыннан «Тәртип» радиосы «Татар никахы» дип аталган проект башлады.

«Хәзер туйлар түгел, ә никах мәҗлес-бәйрәмнәрен үткәрү модага керде. Бу бик яхшы күренеш, ләкин кеше югалып кала, чөнки сораулар күп, ә тулы мәгълүмат алырлык чыганак юк. Шуңа безгә бик күп сораулар килә. Фольклорчылар, дин әһелләре әзерләгән китапларда мәгълүмат табарга була, ләкин кеше җиңел әйбергә күнеккән. Проектның максаты – алтын урталыкны табып, бер кулланма, әсбап булдыру. Дин әһеле, фольклорчы, мәҗлесне алып баручылар үз сүзләрен әйтергә тиеш. Без, барлык якны тыңлап, никах мәҗлесен үткәрү буенча ярдәмлек булдырырбыз дип ышанам», – дип сөйләде радионың баш мөхәррире Ризәлә Исмәгыйлева.

Проект кысаларында беренче түгәрәк өстәл узды. Анда күтәрелгән төп сорау – татар никахы башка халыкларныкыннан нәрсәсе белән аерыла һәм ул нинди булырга тиеш?

«Бу – зур проектның башы. Нәтиҗәсен күрербез, дип ышанам. Татар никахын үткәрү буенча төп әсбап булырга тиеш. Анда, төбәкләргә бәйле рәвештә, һәр якның үз йоласы өстәлер, ә без төп умыртка баганасын ясап куярга тиеш», – дип сөйләде баш мөхәррир.

Түгәрәк өстәлдә Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Россия Мөселман хатын-кызлар берлеге рәисе Наилә Җиһаншина, фольклорчы, филология фәннәре кандидаты Фәнзилә Җәүһәрова, «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисова, «Риваять» этнотөркеме җитәкчесе Руслан Габитов, дини мәҗлесләр алып баручы Марсель Әхмәдуллин һәм Ильяс Халиков катнашты.

Гөлүзә ИБРАҺИМОВА.

Эстәрлебашта юбилей

Башкортстанның Эстәрлебаш районы үзәгендә шушы районның Тормай авылында яшәп иҗат итүче Хисаметдин Исмәгыйлевнең 70 яшьлек юбилее уңаеннан чаралар узды. Татарстан һәм Башкортстан кунаклары түгәрәк өстәлдә катнашты, район китапханәсендә һәм музейда булды. Район мәдәният йортында «Әйтер сүзем бар» дигән әдәби-музыкаль кичә узды.

Әдипне Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, халык шагыйрьләре Марсель Галиев, Газинур Морат, «Казан утлары» журналы баш мөхәррире Рөстәм Галиуллин, проза бүлеге мөхәррире Рафис Корбан, Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстандагы вәкиле Альфред Дәүләтшин, Башкортстан Язучылар берлеге рәисе Айгиз Баймөхәммәтов, Башкортстанда яшәп иҗат итүче татар язучылары – Руслан Сөләйманов, Дилбәр Булатова, Илдус Фазлетдинов, Мөнир Вафин һ.б. котлады.

«Ул – гаярь, туры сүзле, эшлекле, шул ук вакытта нечкә күңелле, ихлас кеше. Юбилеенда моңа тагын бер кат инандык. Якташлары, дуслары алдында

хөрмәтле кеше икәненә сөенеп кайттык. Казандагы төбәкчеләр, тарихчылар белән һәрвакыт элемтәдә тора», – диде Р. Галиуллин.

Мәгълүм булганча, Хисаметдин Исмәгыйлев әсәрләре Татарстан матбугатында даими дөнья күрә. «Мәйдан батырлары» дигән әдәби конкурста «Беренче Сабантуй» хикәясе өченче урын алды. Аның «Никах» кесә китабы «Казан утлары» журналы китапханәсе сериясендә басылып чыкты. «Теле үзенчәлекле, үз стиле бар. Кызлары, оныклары татарча сөйләшә. Оныклары татарча спектакльдә уйнап күрсәтте», – диде баш мөхәррир.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Луганскида милләттәшләр кичәсе

Луганск шәһәренең М.Горький исемендәге китапханәсендә татар шигъриятенә һәм мәдәниятенә багышланган чара узды. Анда Луганск Халык Республикасының төрле урыннарында яшәүче татарлар җыелды.

Бәйрәмне Гөлфия Кәбированың төбәк татар мәдәни үзәге оештырды. Чара Луганск Республикасы Диния нәзарәте һәм төбәкнең Мәдәният, Спорт һәм Яшьләр министрлыклары ярдәме белән үткәрелде.

Татар җәмгыяте вәкилләре туган телнең милләт тарихын һәм ата-бабалар истәлеген саклый торган тиңсез мәдәни мирас булуын күрсәтергә тырышты.

Кунакларга һәм чарада катнашучыларга сәламләү сүзе белән М.Горький исемендәге китапханә директоры Наталья Расторгуева һәм Халык иҗаты үзәге директоры Василий Яровой мөрәҗәгать итте.

«Чишмә» татар-башкорт мәдәни үзәге вәкилләре, «Стожары» халык вокаль ансамбле, «Җаным» татар ансамбле, «Созвездие» хореография ансамбле, Луганск шәһәренең 60 нчы гимназиясе укучылары Индира Садыйкова һәм Ясмин Касыйм, Виктория һәм Мария Драпак гаилә дуэты тамашачыларга иҗади номерлар күрсәтте.

Чараны китап күргәзмәсе дә тулыландырды. Анда татар теле һәм сөйләм мәдәнияте турында кызыклы басмалар, үзәйрәткечләр һәм мәкальләр һәм шигырьләр язылган төрле китаплар тәкъдим ителде.

1 нче биттә – Россиянең атказанган сәүдә хезмәткәре, Ленин һәм Халыклар дуслыгы орденнары кавалеры, татар аш-суын дөньяга таныткан Юныс Әхмәтҗанова багышлап, Теләче районы Олы Кибәхуҗа авылында уздырылган фестиваль-конкурс күренеше. Абдул Фархан фотосы. «Татар-информ».

«Асылташ» кызлар бәйгесе

Казанда республикакүләм «Асылташ» кызлар бәйгесе финалы узды. Конкурсны Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, Казан шәһәре мәгариф идарәсе ярдәме белән 4 нче гимназия-интернат үткәрә. «Асылташ»та 14-18 яшьлек кызлар катнаша. Гимназия директоры Алмаз Ризатдинов сүзләренчә, 2019 елда башланып, ел саен уза торган бәйгенең катнашучылары артканнан арта бара.

«Быел бик күп районнардан гаризалар килде. Финалга Казан, Түбән Кама шәһәрләре, Арча, Кайбыч, Бөгелмә, Әгерже районнары мәктәпләрендә укучы кызлар чыкты», – диде А.Ризатдинов.

Оештыручылар сүзләренчә, «Асылташ» бәйгесе күңел ачу өчен түгел, ә татар халкының йөзек кашы, намусы, киләчәге булырдай кызларны барлау өчен уздырыла. Аның максаты – кызларда гыйлемлелек, изгелек, гаделлек, әдәплелек кебек рухи-әхлакый сыйфатлар тәрбияләү, милли узаң уяту.

Финалга килеп җиткән кызлар, «Тормышымның милли бизәкләре» темасына эссе язып һәм үзләренең уңышларын яктырткан презентация ясап, читтән торып уздырылган этапта сайланып алынганнар. Аларга 5 биремдә көч сынашырга туры килде.

«Нәселебезнең һөнәре» дип аталган этапта кызлар презентация ярдәмендә нәселдән нәселгә күчеп килгән һөнәрләре белән таныштырды.

«Алтын җөй» дип аталган соңгы биремгә финалистлар милли бизәкләрне кулланып, берәр кием элементы яки аксессуар әзерләп килгәннәр һәм аны видео ярдәмендә үзләре эшләгәнен дәлилләделәр.

Телевидение һәм кино режиссеры Нурания Җамалиева «Асылташ» бәйгесендә жюри әгъзасы буларак ел саен теләп катнашуын белдерде. «Асылташ» – башка конкурслардан аерылып тора. Миңа аның иң ошаган ягы – шоуга әйләнмәве. Без монда балаларның белемен, зирәклеген, осталыгын, тел байлыгын күрә алабыз», – диде ул.

Беренче урынга Казанның 4 нче гимназия-интернатының 9 сыйныф укучысы Зәринә Нигъмәтҗанова лаек булды. Икенче урынны өч кыз яулады. Алар: Олы Кайбыч урта мәктәбенең 10 сыйныф укучысы Зилә Рәхмәтуллина, Казанның 20 нче гимназиясенең 10 сыйныф укучысы Зәлинә Сиражеева, Түбән Каманың 13нче гимназия-интернатының 11 сыйныф укучысы Алинә Солтанова. Өченче урынга Казанның 4 нче гимназия-интернатының 9 сыйныф укучысы Эльза Закирова лаек дип табылды.

Рифат КАЮМОВ.

Әдипне искә алдылар

Лениногорскиның Г.Тукай исемендәге Үзәк китапханәдә талантлы әдип, драматург, журналист Шамил Бикчуринның тууына 95 ел тулуга багышланган әдәби кичә узды. Әлеге әдәби-мәдәни чарада аны белгән, аның иҗатын хөрмәт иткән «Чишмә»дәшләре, дуслары җыелган иде.

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, «Чишмә» әдәби берләшмәсе җитәкчесе, Шамил Бикчурин исемендәге премия лауреаты, Лениногорскида туып-үскән Таһир Шәмсуаров үзенең чыгышында Шамил абый нигез салып калдырган әдәби берләшмәне җитәкләве белән горурлануын әйтте.

«Мин беренче тапкыр 15 яшемдә «Чишмә» берләшмәсенә килдем. Мине берләшмәнең ул чактагы җитәкчесе Шамил ага Бикчурин каршы алды. Шушы килүемнән мине берләшмәгә кабул итеп алдылар. Шамил Бикчурин, Җәмит Рәхимов, Альберт Хәсәнов кебек олпат язучылар киңәшләрен тотып иҗат иттем, алар миңа маяк булдылар», – ди Таһир Шәмсуаров.

Лениногорск шәһәренә яңа гына күчеп килгән яшь язучы һәм журналист Шамил Бикчурин 1958 елның октябрендә әдәби түгәрәк оештырып, аның беренче утырышын уздырган. Иҗат оешмасы аның исемен бүген дә йөртә.

Әдәби кичәдә катнашучылар язучының Лениногорск радиосы архивында магнитофон тасмасына яздырылган тавышын тыңладылар.

Татарстан мөфтияте үрнәк күрсәтә

Интернет челтәрендә «Социаль проектлар: планлаштырудан алып тормышка ашыруга кадәр» видеоконференциясе узды. Әлеге чарада Белоруссия, Татарстан һәм Башкортстан мөселман дини оешмаларының социаль эшчәнлек алып баручы, яшьләр хәрәкәтен оештыру белән шөгыльләнүче вәкилләре, шул исәптә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең социаль бүлек җитәкчесе Айгөл Биктимерова катнашты.

Белоруссия мөфтие Әбу-Бәкер Шабанович мөселман дини оешмасы карамагында эшләүче хатын-кызлар хәрәкәте эшчәнлегенә тукталды, социаль проектларны тормышка ашыру буенча тәҗрибәләрне өйрәнү кирәклеккә басым ясады.

А.Биктимерова «MislimMol» мөселман яшьләре хәрәкәте хакында сөйләде. Ул Мөселман яшьләре форумы кышкы мәктәбенең үзенчәлекләренә тукталып, эчтәлеге елдан-ел баюын, быелгы чараның «Эшлә!» шигаре белән яңа форматта үтүен җиткерде. Нәзарәтнең «Зәкят» хәйрия фонды тарафыннан алып барылган хәйриячелек эшчәнлегенә дә аерым тукталып үтте.

Шунысын билгеләп үтәргә кирәк, нәзарәт тарафыннан үткәрелә торган форумнар яшьләргә белемнәрен арттырырга гына түгел, берләшү, танышу, рухи яктан баю һәм үзләренең социаль башлангычларын тормышка ашыру мөмкинлекләрен дә бирә.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте волонтерлар хәрәкәтен оештыру буенча да үрнәк булып тора.

Тәүге очрашу

Башкортстанда Бөтендөнья татар конгрессының вәкиллегендә «Текә татар» проекты кысаларында беренче очрашу узды. Чараның тәүге спикеры Рөстәм Нәбиев булып, аның чыгышының темасы «Авырлыклар аша җиңүгә» дип аталды. Күпләр күңел төшенкелегенә бирелеп, эшкә, укуга булган омтылышларын югалта. Шундый авыр вакытларда гади генә бер сүз, күзгә-күз карап сөйләшү дә бик мөһим була ала. Үткән чара да нәкъ шундый әһәмияткә ия булды. «Максатны ничек дөрес куярга? Каян көч һәм мотивация алырга? Авыр моментларны ничек җиңелрәк кичерергә?» дигән мәсьәләләр күтәрелде. Чакырылган кунак үзенең тормыш тәҗрибәсеннән чыгып һәр кешенең соравына җавап ишеттерде.

Чарага килүчеләр арасында «Нур» татар дәүләт театры артистлары, «Роксана» радиостанциясе, «Туган тел» телевизион каналы хезмәткәрләре, журналистлар, блогерлар, Башкортстан татар яшьләре хәрәкәтенең активистлары бар иде.

Проект авторы Гөлшат Сафина әйтүенчә, Башкортстанда яшәүче милләттәшләребезне берләштерү «Текә татар»ның төп максаты булып тора. Бигрәк тә, яшь һәм урта буынны бергә туплау, фәһемле вакыйгалар аша киләчәккә төпле бер юнәлеш алу. Әлеге проект нигезендә хәзерге заман татар кешесенә кызыклы булган шәхесләр белән очрашулар, җанлы әңгәмәләр ята.

● Джон Рокфеллер 100 мең доллар акча эшләргә һәм 100 яшькә кадәр яшәргә хыялланган: 192 миллиард доллар акча эшләгән һәм 97 яшендә үлгән...

● Greenpease, программалар төзи торган AirVisual компаниясе белән берләшеп, Җирдә иң саф һавалы урыннарны ачыклаган. Иркен сулыш алып була торган илләр исемлегенең беренче дистәсенә Исландия, Финляндия, Австралия, Эстония, Швеция, Норвегия, Яңа Зеландия, Канада, АКШ, Португалия кертелгән.

● Х гасырда яшәгән бөек фарсы вәзире Абдул Касыйм Исмәгыйль китапханәсен һәрвакыт үзе белән йөрткән. 117 мең данә китапны 400 дөя ташыган, алар алфавит тәртибендә урнашкан булган.

● Япониядә поезд биш минутка соңарса, пассажирлардан рәсми рәвештә гафу үтенәләр, кайвакыт исә эш урынында күрсәтү өчен соңару турында белешмә дә бирәләр. Поездның бер сәгатькә соңга калуын исә күз алдына да китереп булмый.

ҮТЕРҮЧЕ КЕМ?

яки Беренче татар детективы

Кариев театрында мәет табалар, дөресрәге, сәхнәдәге мосафирханәдә бер кызны үтереп ташлыйлар. Кариев театрында да түгел, С.Өметбаев исемендәге Минзәлә Татар дәүләт драма театрында. Кариевләрнең исә моңа ни катнашы бар? Минзәлә театрының Казандагы гастрольләре вакытында бер спектакльләре Кариев сәхнәсендә куелды. Аны яшьләр театрының баш режиссеры Ренат Әюпов иҗат иткән.

Фани дөньяда нибары 32 ел гына яшәсә дә, язучы Заһир Бигиев язма ул чор татар әдәбиятына хас булмаган реалистик романнары, детектив жанры белән кереп кала. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романын нибары 17 яшендә иҗат итүе билгеле. Татар әдәбиятында беренче детектив әсәр, татар сәхнәсендә тәүге детектив спектакль күрсәтелә, дигән хәбәр Казан тамашачысын кызыксындырган, күрәсең, көндезге куелышта да, кичке спектакльдә дә зал шыгрым тулы иде.

Классик әсәрләр хәзерге заман тамашачысына кызык түгел, дигән сүзгә моннан соң ничек ышанмак кирәк? Ничек кенә кызык әле! Куючылары гына булсын. Режиссер Р.Әюпов классик мирасыбызга хөрмәте белән театр сөючеләрнең күңелен инде күптән яулады. Инсценировканы да үзе ясый, үзе үк сәхнәгә куя. З.Бигиев әсәре – Р.Әюповның Минзәләдә генә дә сигезенче спектакле. Режиссерның иҗат куәсен күз алдына китерү өчен бу театрда сәхнәләштергән «Сөннәтче бабай», «Остазбикә», «Мөһаҗирләр» исемнәрен әйтеп үтү дә җитә. Сүз уңаеннан, әдәбият классигы, милли каһарманыбыз Гаяз Исхакыйның иҗатына зур игътибары өчен 2005 елда Минзәлә театры коллективы М.Җәлил исемендәге премия белән бүләкләнгән иде. «Сөннәтче бабай» минзәләлеләрне Төркиянең Конья шәһәрендә узган халыкара фестивальгә кадәр илтеп җиткерде.

«Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» әсәрендә вакыйгалар 100 мең акча белән гүзәл Хәдичәне хатынлыкка алырга хыялланган Казан байлары Муса һәм аның дусты Габденнасыйр тирәсендә әйләнә. Мусага үлеп гашыйк Кырым кунагы Зөләйха туташның үз-үзен үтерүеннән файдаланып, Габденнасыйр Мусаны өтермәнгә олактырмакчы, үзе акчалы да, кәләшле дә булмакчы. Иманнарын акчага сатса, хатын-кызны байлык, дәрәҗә чыганагы, мал итеп караса да, никтер күңелгә хуш килә бу егетләр. Завод, фабрика тотучы Казан байларының Петербургта университет тәмамлаган уллары булганга күрә түгелме икән? Шулай туры киләдер инде, татарны сәхнәдә күбрәк йолкыш крестьян итеп күрәбез. Монда исә – түшләрен киергән байлар. Аларның горур атлап сәхнә буйлап йөрүләрен күрү өчен генә дә спектакльгә килерсең.

«Дөп-дөп» уйнаган музыка, кисәк сүнеп янган сәхнә утлары, сәхнәдәге газета сатучыларның акырынып әрле-бирле йөрүләре иң башта ук детектив жанрына хас киеренке халәтне билгеләп куя. Газета сатучыларның вакыйгалар барышында сәхнәгә мең чыгып, мең керүе, шуңа өстәп фотоаппаратларның пистолеттан аткан тавыштан ким булмаган «чалт-чолт» авазлар чыгаруы, паровоз гүелдәве киеренке халәтне ахыргача сакларга ярдәм итә. Режиссер Р.Әюпов һәрвакыт яшьләр иҗатына игътибарлы булды, бу юлы да яшьләрне иҗатташлыкка алып уңган. Спектакльнең музыкаль бизәлешен Йосыф Бикчәнтәев башкарган, пластиканы Марат Казыйханов иҗат иткән, сәхнә сурәтен рәссам Булат Гыйльванов эскизлары буенча эшләгәннәр. Спектакльдә шәрык музыкасы аһәңе XIX гасыр ахырын тоемларга ярдәм итә. Бай егетләрнең бөркет сыман горур биюләрен күрер өчен генә дә, ярты малыңны бирерсең. Бүген күпчелек ансамбльләребездә ир-ат артистлар да «иләилә-иләлә»гә бии. Боларның исә биюләре дә байларча. Гомумән, бер пәрдәлек, җыйнак кына булса да, спектакльдә музыка күп янгырый. Режиссер милли җыр, музыка сәнгатебезне, гадәт-йолаларны күрсәтү өчен бөтен мөмкинлекләрдән файдалана. Бу спектакльдә милли гореф-гадәтләр Хәдичәне ярәшү күренешендә матур булып чагыла. Ул вакытта сәхнәдәге милли бизәкләрдән, матур җырлардан һуштан язарлык. Р.Әюповка гына камил җырлый белгән актерлар ничек туры килә, дигән? Минзәлә артистларын шундый итеп җырлата ки, дәүләт җыр һәм бию ансмабле җырчыларыннан аерырлык түгел үзләрен!

Детектив нигезендә яшерен сер ята. Вакыйгаларны йон йомгагы сыман сүтеп, серне ачасы бар. Сәхнә бизәлешләрендә анда-санда йомгаклар тикмәгә эленмәгән, димәк. Келәм туку станы һөнәрчелек үскән чорны тоярга ярдәм итә. Видеограф Максим Кунинның ярдәме белән туку станы үткәндәге вакыйгаларны яңартучы көзгегә әйләнә. Спектакльдә күп нәрсә шартлы булса да, бер максатка – XIX гасыр ахырын күз алдына китереп бастыруга уңышлы хезмәт итә. Геройларның извозчик яллап, шәһәр буйлап җилдерүен, паровозда мәрхүмә Зөләйханың әнисе янына Кырымга баруларын күрсәтү кечкенә генә театр сәхнәсендә мөмкин эшме? Р.Әюпов тотынса, тормышка ашырырга мөмкин булмаган күренеш юк ул!

Минзәлә театры артистларын тирән психологик күренешләрдә сокланып караган бар. Әмма бу спектакльдә алар махсус артык тирәнгә кермичә, шартлы бер стильдә уйный кебек. Бу да – чор сурәте, беренче театрларның нинди булганын күз алдына китерә торган сурәтләү алымы булса кирәк.

XIX гасыр байлары тормышыннан алып иҗат ителсә дә, З.Бигиевнең бу әсәре бүген генә язылган кебек. Симезрәк калҗаны эләктерү өчен ике татарның бер-берсен батыруы, ни кызганыч, искерә торган сюжет түгел...

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга
10 март
№9, 2023

ТАСЫЛЫН БЕЛГӘН – ТАШ СЫККАН

– Әссәламегаләйкем!

Дикъкать белән карасам, куаклар артыннан килүче малай күренде. 103 мәктәпнең 2 нче сыйныфы укучысы Искәндәр икән.

Бу мәктәп укытучылары белән аралашып яшим. Искәндәр белән очрашкан көнгә дә инде 8 ел узып киткән. Алар сыйныфы быел 10 нчыда укый. Яңа Савин районындагы 103 мәктәпнең беренче татар сыйныфын башлап җибәрүче алар.

Ул сыйныфны ачуга тырышлык өчен күпме яну кирәк булуын милли мәсьәләләр буенча директор ярдәмчесе Мәдинә Әбделганиева белән Сылу Вәлиева гына беләдер. Аларга башта күпме ата-аналар белән очрашып, изге туган телебез хакында сөйләргә, татар классларында укучыларын әзләп табарга кирәк була әле. Көндез генә түгел, төнлә дә йөри алар. Теләккә ирешү өчен киткән эшчәнлек бушка китми. 1 сентябрь көнне 25 сабый баланы каршы алып, дәресләрдән соң озатып җибәргәндә, күзләренә яшьләр килә Сылу ханымның. Ә бу 1990 елның көзе иде.

Ә бүген әлеге мәктәптә 19 татар сыйныфы гөрләп гыйлем ала.

Тасылын белгән – таш сыккан, диләр. Ә ташны сыгу өчен гайрәт, эшчәнлек, сабырлык, акыл кирәк. Әйе, сыга Мәдинә Хәниф кызы ташны. Чөнки халкыбызның рухи хәзинәләрен киләчәккә илтәсе бар. Шул максатка ирешү өчен каршылыклар алдында да туктап калмый. Эчендәге ялкынын диңгезгә салса, диңгез кайнап чыгар көннәрә була аның. Ярасына баскач, телсезләр дә кычкыра бит. Ә аның ярасы – туган телне саклау, балаларны туган телдә тәрбияләү, халкыбызның гореф-гадәтләрен җаннарына сеңдерү. Шул теләктә янып, күп төрле чаралар, очрашулар уза мәктәптә.

Каюм Насыйри исемендәге бүләк лауреаты Мәдинә Хәниф кызы – искиткеч шәхес. Үзе дә яна, башкаларны да ялкыны белән дөрләтә. Оештыру эшләре буенча осталыгы зур. Нинди генә очрашулар әзерләми! Каян килә мондый көчкуәт? Бәлки, күңелендә Гаяз Исхакый рухы яшидер. Исхакыйның нәсел башы – Чирмешән ягыннан бит! Мәдинә дә Чирмешәннән.

Очрашуларга ул күңел нурын тыңлаучылар күңеленә сала белүче шәхесләрне чакыра. Язучы М.Хәбибуллин, галимнәр Р.Әмирхан, Мәхмүт Әхмәтҗанов, күп илләр гизгән Александр Михеев (ул мөселман), галим һәм язучы Ф.Яхин, академик Илдус Таһиров, тирән белемле Рамил хәзрәт, композитор М.Шәмсетдинова, профессор Ф.Сафиуллина, филология фәннәре докторы Р.Ганеева, Тукай бүләге лауреатлары Ф.Әхмәтова-Урманче, батыр һәм горур шагыйрь Ф.Яруллин кичәләре, «Карга баткалары», Нәүрүз бәйрәмнәре, Кич утырулар, «Аулак өй»ләр үткәрү... Әле күңеле киң Мәдинәнең, яңа очрашулар эзли ул!

Бу кичәләргә ата-аналар да чакырыла. Чөнки Мәдинә Хәниф кызы белә: балада тел, әдәп һәм иман тәрбияләүдә ата-ана һәм укытучы аерылгысыз. Балалар да, ата-аналар да, укытучылар да очрашулардан ямь алып, күңелләре яктырып, әдәп турында яхшы сүз ишетеп, горурланып кайтып китә. Очрашулар йөрәкләргә уелып кала. Шәҗәрәләр турындагы кичә, әле дә искә төшкән саен күңелләрне яңгыратып тетрәтеп ала.

Апрель ае. Табигать яшәргән чак. Бар дөньяны яшеллеккә күмеп яз килә. Шундый матур кояшлы көндә халык зур мәҗлесләр залына җыела. Район, шәһәр укытучылары, ата-аналар, укучы балалар, академик, галим, тарихчы да, музей хезмәткәрләре дә бар.

Залның бизәлеше – шәҗәрәләр турындагы плакатлар, нәсел-ыру тарихлары, альбомнар, балаларның да үз нәселләрен төзегән шәҗәрәләре... Иң уртада Мәдинәнең үз нәсел-ыруының 11 буынга кадәр житкән шәҗәрәсе тора. Илдус Гыйләҗевнең шигырь юллары яңгырый:

– Катнаш никах арта барган саен,
Урыс «бажай» үрчи, шәбәрә.
Безнең чорда бетә, юкка чыга
Гасырлардан килгән шәҗәрә.
«Насыйп эше», – диеп әйтсәләр дә,
Нә табигый, сына тәһарәт.
Дөньялыкта тату яшәсәң дә.
Икеңә бит ике зиярәт...
Кем фатиха бирә белә торып?
Уртак юл бит сына, өзелә.
...Ни оятың җитеп күренерсең,
Көне җиткәч, Раббым күзенә?..

Шәҗәрәләр, нәсел, туганлык турында чираттагы чыгыштан соң, Тукайның «Туган тел» көе агыла башлады. Бөтен зал тынды. Мәдинә Хәниф кызы татар классларында укучы балаларны залга чакыргач, алар «Туган тел»не җырлый-җырлый, кыр казлары кебек тезелеп, залга килеп кергәндә күңелләр урыныннан ычкынды, җаннар тетрәнде, күңелләргә мөлдерәмә яшь тулды. Соңгы сыйныф кереп тантана залын урап алганда да күз яшьләре туктамаган иде. 10 татар классы! 250 укучы! Алардан киләчәктә шушы халыкка хәзмәт итүче, рухи хәзинәбезне кадерләүче күпме буыннар тәрбияләнер әле!..

Мәдинә Хәниф кызына гаҗәпләнү катыш сокланам мин. Авырулар да килерде ул. Ләкин милләте өчен яну дәртен йөгәнләрлек түгел. Мин әле хәтерлим. 1991 елның язы иде. Көз ачылган татар сыйныфы санын алдагы елларда арттыра барырбыз дигән максатны ашыру юлларын эзләү өчен, җитәкчеләр, ата-аналар, укытучылар мәктәпнең актлар залына җыелды. Татар классларын ачу турында сүз кузгалгач, фикерләр икегә бүленде: тавыш, гауга, шау-шу купты. Хәтта: «Нигә бу кадәр дау күтәрәсез? Сугыш елларында эвакуацияләнгән урысларны җылы кочагыбызга сыендырдык, ризыгыбызны бүлдек, ә сез...» – дип, сөйләүченең кулыннан микрофонны тартып алдылар. Укытучы Сылу: «Безне бетерәләр анда, әйдәгез тизрәк!» – дип, Мәдинә Хәниф кызының өенә йөгереп килде.

Әле авырудан аягына рәтләп басмаган Мәдинә Әбделганиева халык алдына килеп басты һәм тыныч караш ташлап болай диде:

– Әллә без урлап тотылдыкмы? Безнең нинди гаебебез бар?! Ирем хәрби врач булганлыктан, миңа Ак һәм Кара диңгез буйларындагы шәһәрләрдә яшәргә туры килде. Милли мәсьәләдә «ак»ны карадан аерырга шул елларда өйрәндем. Ул халыклар арасында җирле халыкны шушы кадәр кимсетүне, түбәнсетүне күрмәдем. Без телебезне югалттык инде, югалтып барабыз. Ә сез нәрсә югалттыгыз? – дигәч, халык сүзсез калды. Җыелышта «Мәгариф» комитеты әгъзалары белән аның җитәкчесе Гали Даутов та катнашты. Мәрҗәни жәмгыяте президенты Зәки Зәйнуллин да килгән иде. Татар классларын ачтыруга каршылык күрсәткән җитәкчеләр: «Монда түгел, монда булмаячак, күрше мәктәпне гимназия итеп үзгәртәбез», – дигән вәгъдәләрен бирергә мәҗбүр булды.

Күршедәге 13 татар гимназиясенең ачылуына сәбәп булучылар да 103 нче мәктәп укытучылары белән «Мәгариф» комитеты әгъзалары иде. Менә шулай эшли-эшли бүгенге көнгә килеп җитте алар. «Кешенең бөеклеге – аның фикерләү сәләтендә», – дигән Б.Паскаль. Әйе, менә шулай тирән белем һәм акыл белән кешеләр күңеленә тәэсир итә белгәнгә, 19 саф татар классы җыя алды инде ул. «Милли мәсьәләләрне хәл итү, тормышка ашыру – тоташ каршылыкларны җиңә бару ул», – дигән иде Мәдинә Хәниф кызы. Шулайдыр, югыйсә, ел саен арта бармаслар иде.

Әлбәттә, барлык бу эшләрне Мәдинә таяныч та, дус та булган укытучылары белән бергә башкара. Татар теле белгечлеге буенча эшкә алганда, нинди догалар укыйдыр, укытучыларның да аларга гел сөйкемлеләре җыелган. Әнә, йомшак күңелле һәм сабыр Әнвәрә, һәрчак ярдәмгә әзер Римма, йөзеннән нур бөркелүче Гәүһәр, елмаеп үзеннән җылылык таратучы Раидә, гел каядыр ашыгучы, әйдәп баручы укытучы Сылу, үзеннән һаман яктылык таратучы Дилбәр, исеме җисеменә туры килгән көләч йөзле Зөләйха, айсыз төндә нур булып сирпелерлек Зөһрә, «телең татлы, бер генә сүз дәш әле» дип торырлык Әминә, киң күңелле, мөлаем Фирая, кергәннән гөлләр тамдыручы Нурзилә, бала күңелендә горурлык сыйфатларын тәрбияләүче Сания – барысы да укытучы булу өчен яратылган.

Ятим балалар йортына барып, җылы сүзе белән ятимнәрне сөеп, күчтәнәчләр белән сыйлап кайтырга да вакыт таба Мәдинә ханым. Әлбәттә, тормыш гыйбрәтләрен күрсеннәр дип, мәктәп балаларын да үзе белән ала. Ятимнәр язмышы белән күзгә-күз очрашу йөрәкләрне тетрәндерә бит ул. Тетрәнеп кайтсыннар, киләчәктә үз балалары шушы көнгә калмасын дип эшли ул боларны. Шуңа күрә Мәдинә үрнәгендә мәктәптә балалар белән укытучылар арасындагы мөгамәләдә җылылык саклана. Шәфкатьлелек, миһербанлы булу, кызгану хисләре тәрбияләүдә бу мәктәп укытучыларына бәя куя алмыйм. Балаларга назлы караш башлангычтан ук башлана.

Бу мәктәптә китап та яраталар. Китапка соңгы акчаларын түлиләр. Яхшы китап булса, бүләк итәргә ашкынып торучы Мәдинә Хәнифовна беренче үрнәк күрсәтә. Аның ата-аналар җыелышында ясаган чыгышларын да тыңлаганым бар. Күп сөйләми, ләкин ихлас сөйли. Асылташтай мәгънәле сүзләрне эти-әниләр күңеленә тезә бара. Ә алар игелекле туфракка утырткан гөлдәй, эти-әниләр күңелендә тамыр җибәрә.

Россия Федерациясенең мәгариф отличнигы, әйдәп баручы укытучы гына түгел, хатын-кыз да, ана да бит әле ул. Ире – табиб. Бер егет, бер кыз үстергәннәр. Икесе дә югары уку йортларын тәмамлап ватанга хезмәт итә. Ата-ананың кемлеген белəсəң килсә, балаларына кара, диләр. Балалары да тәүфыйклы, иманлы аларның. Йөзгә кызыллык китерә торганнардан түгел!

Мәдинә ханым бүген шатланып эшли. Хәзергене киләчәккә илтүче 429 татар уллары һәм кызларының үз туган телебездә тәрбияләнүләрен күрү, рухи хәзинәбезне өйрәнеп үсүләрен белү йөрәк сыкрауларына дәва түгелмени?!

Кагылмагыз, пөхтә торсын
Халкым узган юллар даны.
Болганмаган, чиста әле
Дәвамында татар каны!
Әйе, дәвамында татар каны!
– Юл бирегез!

Розалия ШӘМСЕТДИНОВА.
Казан.
2012 ел.

АВЫЛДАШЛАР СӨЛГЕ ҖЫЯБЫЗ

Борынгыдан килгән изге йола,
Тамырларда аны тоябыз.
Бәйрәм рухы таңнан күңелләрдә –
Авылымда сөлге җыябыз!

Һәрбер йортта йомыркалар көтә,
Чиләк белән җыя малайлар.
Сөлге таккан кыңгыраулы атын
Каршы ала ачык капкалар!

Кызлар кулъяулыгы колгаларда,
Нәфисләгән аның кем сөйләр.
Кыз сөлгесе, килен сөлгеләре
Болындагы гөлләр төсләләр!

Сөлге җыйган атның арбасында
Гармун тарта җиткән егетләр.
Янәшәдә барган сылукайлар
Хан кызыннан кайтыш түгелләр!

Туй бүләксез узмыйни инде,
Хәзинәдә барын бирәбез.
Ә бу сөлге баш батырга булыр –
Пар күгәрчен анда күрәбез!

Сабан сүзе йөрәк түрләрендә,
Ил тоткасы белән, сабаннар.
Юк, бүген дә әле кара җирнең
Җылылыгын сизә табаннар!

Борынгыдан килгән изге йола,
Бер горурлык җанда тоябыз.
Һәр йөрәктә бәйрәм рухы бүген,
Авылдашлар сөлге җыябыз!

БАЛА КҮҢЕЛЛӘРЕ АНАДА

Әни күңеле, әйе, балаларда,
Баланыкы, имеш, далада.
Беләсезме, юк, далада түгел,
Бала күңелләре анада!

Килешәмен, халык белми әйтмәде,
Безне уйлап яши аналар.
Читтә гомер сөргәннәрдән сора,
Әни диеп яши балалар!

Әни тапкан, әни баккан безне,
Истә тора сиртмә бишекләр.
Әти барда, әни исән чакта,
Көне-төне ачык ишекләр!

«Сау бул, балам, имин йөре!» – ди ул,
Хәтерләрдә әйткән сүзләре.
Тәрәзәдән олы юлны күзли,
Кайтыр диеп әнкәй күзләре.

Кай тарафта гомер сөрсәләр дә,
Каладамы, әллә далада,
Бала күңеле, юк, далада түгел,
Бала күңелләре анада!..

БИШЕКЛӘРДӘ ҮСМИ ОНЫКЛАР

Бик еш кына борчу били мине,
Була шундый моңсу минутлар.
Безнең сыман бишек җырын тыңлап,
Бишекләрдә үсми оныклар!

Китап киштәсендә әкиятләр,
Сагыналар малай-кызларны.
«Таңбатыр»лар, «Гөлчәчәк»ләр белән
Дуслаштырыйк әле аларны.

Май җиттеме, авыл урамнары
Юксынуга никтер таралар.
Хатфә чирәмнәрдә рәхәтләнеп,
Уйнамыйлар нигә балалар?!

Болыннарда тайлар кешнәмиләр,
Кайда калды ярсу байталлар?!
Куе ялларыннан сыйпамыйча,
Атсыз үсә бүген малайлар!

Таң атуга Алсу, Азаматлар
Телефонны кулга алалар.
Сабыйлыкның тиңсез матурлыгын
Ни кызганыч, күрми калалар!

Бик еш кына бер уй били мине,
Була шундый моңсу минутлар.
Әнисенең бишек җырын тыңлап,
Бишекләрдә үсми оныклар!..

КАРА АЛТЫН ИЛЕ

Минем ягым кара алтын иле,
Кара җире, кара туфраклы.
Игенченең маңгай тире тамган
Туган яксыз яшәп булмады!

Кырык өчтә сугыш бара иде,
Онытылмас белән, гомергә.
Кара алтын күккә күтәрелде
Сигез ярым чакрым Шөгердә!

Хәзинәне тапкан якташларның
Ил каршында бүген йөзе ак.
Җир шарында данлы-дәрәҗәле
Татарстан дигән туган як!



Таһир ШӘМСУАРОВ

Әнисенең бишек җырын тыңлап, Бишекләрдә үсми оныклар...

Җыр һәм шигырь атлый янәшәдән,
Юк, тынмады тальян гармуннар.
Гасырларны кичкән «Шөгер» җырын
Киләчәккә илтер хакым бар!

Бар-барлыгы йөрәк түребездә,
Көне-төне ачык капкалар.
Тамыр тарта, сагынуга түзми
Киткәннәр дә кире кайталар!

Туган җирем кара алтын иле,
Көтеп алам аяз һәр таңны.
Яратмыйча яшәп кара менә
Татарстан дигән Ватанны!..

КЕШЕСЕЗ УРАМ

Кычытканга ялгыз кагылсаң да
Яшел яфрагыннан моң ага.
Кайтырлар дип бары тәрәзәләр
Өмет белән карый дөньяга.

Һәрбер өйдә күпме истәлекләр,
Кай тарафта көләч минутлар?!
«Әби, бабай» диеп, йөгерешеп
Кайтып керми инде оныклар.

Ә бирегә беркем хатлар язмый,
Телефон да, монда ут та юк.
Җаны барлар белән, ишетәдер:
Өй анасы елый сулыгып...

Авыр, моңсу тынлык хуҗа монда,
Картлар китеп барган буш өйләр.
Тормыш монда күптән сүнгән инде,
Яратмыйлар монда, сөймиләр.

Кычытканга ялгыш кагылсаң да,
Яшьле яфрагыннан моң ага.
Тик шомыртлар майда чәчәк тотып,
Өмет белән карый урамга...

КӨНБАГЫШ

Син июльдә таҗларына кагыл,
Юкка чыга җанда бар сагыш.
Туган җирнең тиңсез чәчәге син,
Рәхмәт сиңа, көләч көнбагыш!

Бер гүзәллек үзенә тарта таңнан,
Елмаюлар били шул чакта.
Вакыт табып, кырга чыга калсаң,
Көнбагышлар ала кочакка!

Телең белән әйтеп биралмаслык
Бер ярату хисе бар анда.
Көнбагышлар озатып кала мине,
Каршы ала, балкып кайтканда.

Кара төндә сукмак эзләгәндә,
Шулай булыр диеп кем әйтә?!
Сине көтеп торган сары сердәш
Авылыңа юлны күрсәтә.

Бу басуга шатлык оялаган,
Һәр тарафтан бәхет ургыла.
Әйтерсең лә кояш җиргә төшкән –
Тирә-ягым тоташ нур гына.

Туган якның җәйге чәчәге син,
Илһам бүләк иткән көнбагыш.
Син июльдә таҗларына кагыл,
Юкка чыга җанда бар сагыш!..

МӘЙДАННАРДА ГӨРЛИ САБАН ТУЕ

Кара бураздан атлаганда,
Изге җир дип йөрттек без аны.
Сабан туе матур узсын дисәң,
Яратырга кирәк сабанны!

Егет халкы таңнан урамнарда,
Чиләк тотып йөгерә малайлар.
Яшь киленнәр күптән сөлге чиккән,
Түбәтәен барлый агайлар!

Ә авылның уналтыда чагы,
Сылу кыздай көяз бизәнгән.
Ишетәсеңме, кемдер җырлый әнә,
Моңлы тавыш килә үзәннән!

Бәйрәм ашы кайный казаннарда,
Бар төбәктән җыела милләтем.
Гармунчылар гармун сайратсыннар,
Өлге итеп халык көйләрен!

Милләтемнең менә ел буена
Бәйгеләрне көткән чаклары.
Күңел тула, горурланмый кара,
Исән, шөкер, татар атлары!

Һәр ызбага кунак кайта бүген,
Кояш көнләшерлек якты уй.
Гасырлардан килгән мирас исән-
Мәйданнарда гөрли Сабантуй!..

ӨМЕТ

Өчпочмаклы хатлар килми инде,
Айлар түгел, еллар үтсә дә.
Соңарган хат сузар төсле миңа
Хат ташучы, үтеп киткәндә...

Кыш узуга, язда кабат кайта,
Бөреләнә яңа өметләр.
Өйдәгеләр өзелеп көтте сезне
Кайтам диеп киткән егетләр!

Хәбәрсезләр, хәбәр җибәрегез,
Кай туфракта ята кайсыгыз?!
Тол хатыннар сезне күрми калды,
Оныклар бар әле, кайтыгыз!

Исемнәрен барлыйк һәйкәлләрдән,
Ялгыш кемдер төшеп калмасын.
Ватан-ана, юк, оныта алмый
Яуда башын салган баласын.

Җиңү алып кайткан батыр ирләр
Сез мәңгегә хәтер түрендә.
Каһарманга ничек баш имисең –
Кояш балкый илем күгендә!

Өчпочмаклы хатлар килми инде,
Айлар түгел, еллар үтсә дә.
Соңарган хат ишек шакыр төсле,
Безнең турдан үтеп киткәндә...

САҖИДӘСЕН ТАТАР САГЫНА

Шагыйрә Саҗидә Сөләймpraнованың якты истәлегенә

Тезелешеп кошлар китеп баргач
Вакытлыча торыр ягына,
Каен яфраклары телгә килә:
«Әлмәт Саҗидәсен сагына!»

Ул болай да бәгырьләрдә иде,
Көткән бер моң иде һәр өйдә.
Басмасыннан офыкларга багып
Керләр чайкый иде Саҗидә!

Холкы шундый, халкы шундый инде.
Карый җиргә көзе моңаеп.
Онытмаган газиз халкым, диеп,
Күр, Саҗидә карый елмаеп.

Шагыйрьләргә шулай язылгандыр:
Ак каләмен хискә мана да,
Гасырларның күрке саналырлык
Җыр калдыра чиксез җиһанда.

Игезәге иде ул өметнең,
Язны күрде кышның карында.
Тел – мәңгелек, яши, яшәячәк,
Нәни иле-авыл барында!

Кайберәүләр Тукай исеменнән
Кабаланып бүләк алганда,
Шагыйрәсе белән күрешергә
Татар килә шушы мәйданга.

Тезелешеп кошлар китеп баргач
Вакытлыча торыр ягына,
Күзгә яңгыр туры җанга тама,
Саҗидәсен татар сагына!

Лениногорск районы,
Мөэмин-Каратай авылы.

● «Галиябану, сылуым иркәм» спектакленнән соң.

АВЫЛДАШЫМ

Мин – Нәҗибәнең авылдашы. Безнең авыл бик кечкенә иде, егерме-утыз йорт булгандыр. Чәлтерәп аккан чишмәләрне, таллар, зирек агачларын, әкрен генә аккан инешне күз алдына китерегез. Тау битләрендә кызарып пешкән җиләк, мәтрүшкә, исле гөлләр, бер сүз белән әйткәндә, үзенә күрә бер оҗмах инде. Безнең авыл кешесенең чиста, намуслы булуы әллә кайдан күренеп тора. Авыл бәләкәй булгач, бөтен кеше синең кем икәнеңне белә, беркемнән бер нәрсәне дә яшерә алмыйсың.

Менә шул кечкенә генә Яңа Ташлыяр исемле авылда әнисе Миңнежамал, әтисе Гыймаделислам гаиләсендә Нәҗибә дигән кыз дөньяга килә. Нишләптер, мин Нәҗибәнең мәктәптә укыган чагын ныклы хәтерләмим. Без беренче, икенче, өченче класс укучылары барыбыз бергә укый идек. Укытучыбыз Сәхипҗамал абый. Соңга калсак: «Әбрәкәй сандугачы, килдең дә мени?» – дип мыскыл итә иде. Авыл кечкенә булгач, хәтта радио да юк. Мин инде театр, артистлар, җырчылар турында сөйләп тә тормыйм. Аларны күргән дә, ишеткән дә булмады. Шулай да без Яңа елны, Октябрь бәйрәмнәрен үзебезчә матур итеп уздырырга тырыша идек. Шунда мин Нәҗибәнең җырлавын беренче мәртәбә ишеттем.

Өченчене бетергәч, Буралы авылына укырга йөри башладык. Бездән 3-4 чакрым. Минем уку әйберләремне сала торган әнкәй тегеп биргән букчам бар иде. Малай кеше бит, шул букчаны Нәҗибәнең муенына асып куям, ул аны күтәреп кайтырга тиеш. Бер көнне чокыр буенда, бу минем букчаны алып ыргытты. Мин ачудан аны чокырга төртеп төшердем, шунда ул карга күмелеп юкка чыкты, чокырдан тартып чыгарсам, бөтен бите сыдырылып беткән. «Тагын шулай эшләсәң, этигә әйтеп, җаныңны алдыртырмын», – диде. Әтисе Гыймай абый бик кызу канлы кеше, аның кулына эләксәң, күрмәгәнеңне күрерсең. Әтисенә әйтәм дигәч, нык курыктым инде. Ярый әле әйтмәгән, үз букчамны үзем күтәреп йөри башладым. Шуның белән безнең мәхәббәт тә үлде.

Буралыда 7 классны бетергәч, егерме чакрымдагы Чалпы урта мәктәбенә укырга йөри башладык. Егерме чакрым җирне җәяү, яңгыр дими, кар дими, кыз бала ризык күтәреп укырга йөрсен әле! Бүген мондый хәлне күз алдына да китерү мөмкин түгел. Өстәвенә, җыен ир балалар арасында Нәҗибә бер үзе иде бит.

Бервакыт язгы каникулга чыктык. Матур, кояшлы көн. Чалпыдан Чуар Абдул авылына килеп җиттек. Карасак, Мәлләне язгы ташу баскан, боз өстеннән шундый көчле су ага, нишләргә белмибез. Суны ерып чыкмасак, авылга кайтып булмый. Ә су артканнан-арта гына бара. Буралы малайлары түзмәде, аяк киемнәрен, чалбарларын салды да, кулларын өскә күтәреп, берсе артыннан берсе әкрен генә чыга башлады. Мин Нәҗибәгә карап торам, нишләр икән? Ул да аяк киемнәрен салды да, күлмәген күтәреп бәйләде. Шулай әкрен генә су ерып чыга башладык. Теге яктан малайлар өйрәтеп тора. Кинәт Нәҗибәнең аягы таеп китте, көчкә тотып калдым, әгәр малайлар ярдәм итмәсә, икебез дә агып китә идек. Ярга чыгуыбыз булды, су көчле ташкын булып күтәрелеп китте, әгәр чыгып өлгермәгән булсак, батып үлә идек. Менә шунда күрдем Нәҗибәнең нинди кыз бала икәнен. Кем язгы ташу вакытында Мәлләгә керә инде? Яшьлек-җүләрлек бу.

Нәҗибә бик тырышып укыды, тәртипле дә иде, аларның гаиләсе барыбызга да үрнәк булды. Менә 10 нчы классны да тәмамладык. Хәзер инде исәп – ничек тә Казанга барып, институтка укырга керү иде. Кызык замана: институтка керәм дисәң, колхоздан справка алырга кирәк, димәк, рөхсәтне дә колхоз гына бирә. Справкаң булмаса, паспорт бирмиләр, паспортың булмаса, институтка керә алмыйсың. Шуңа күрә колхоз рәисе Канәгать абый янына Буралыга идарәгә бардык. Безгә аны, басуда тракторчылар янында, шуннан эзләгез, диделәр. Басуга чыгып киттек, эзлибез-эзлибез, бер кайда юк. Ниһаять, ат өстендә Канәгать абый күренде, сөргән кара җирдән юыртып кына бара. «Канәгать абый! Безгә укырга керергә, зинһар, справка бир инде», – дип, ялына башладык. Ул ат өстеннән генә: «Справка бирсәм, колхозда эшләргә кем кала?» – дип котыбызны алды. Нәҗибә белән артыннан елыйелый чапканны күргәч, түзмәде ахры, иртәгә иртән идарәгә килегез, диде. Без шуны аңладык: әгәр син авылда тугансың икән, синең киләчәгең маңгаеңа язылган, кол булып тугансың – кол булып үләсең. Рәхмәт инде Канәгать абыйга, әгәр ул җибәрмәгән булса, без нишләр идек?

● «Гөргөри кияүләре».

Казанга бару мәрәкәсендә Нәҗибәне искә төшерәсем килә. Аның белән иртүк чыгып киттек. Башта Сарманга барабыз, аннан Чаллыга, шуннан пароходка утырып, Казанга китәбез, янәсе. Авылдан чыгып Карамалыга җиткәндә, көчле яңгыр купты. Өс киемнәребез манма су, аяк киемнәребезгә кара балчык чабатадай ябыша, куптарып алмалы түгел. Атлап булмый башлагач, Нәҗибәгә әйтәм: «Болай барып булмый, әйдә, аяк киемнәрен салыйк та, берәр җиргә яшереп куйыйк». Рангазар күперенә җиткәч, аның астына төштек тә, аяк киемнәребезне беркем дә күрмәслек итеп яшердек. Нәҗибә карышып маташкан иде, кайтканда кереп алырбыз дип, көчкә күндердем. Аяк киемнәрен салгач, шулхәтле рәхәт, җиңел булып китте, пычрак сизелми дә. «Әйдә, Рангазарга кереп тормыйбыз, басу аркылы Сарманга барабыз, югыйсә, бүген Чаллыга җитә алмыйбыз», – дим. Ашлык басуы аркылы бара-бара эштән чыктык, яңгыр ява, кулыбызда зур-зур такта чемоданнар. Ахыры, Сарман тавына килеп җиттек. Сарманда самосвал машинасына утырып, тимер әрҗәдә эштән чыга-чыга, көч-хәл белән Чаллыга килеп кердек. Пристаньда аяк-кулларны юып, пароходка утырдык. Нәҗибә бу җәфаларга ничек түзгәндер, әле булса аңлап бетерә алмыйм.

● «Кичер мине, әнкәй».

НӘҖИБӘ

● «Әниләр һәм бәбиләр».

Бер кызык хәл дә булды. Пристаньнан чыгып, трамвайга утырабыз дигәндә генә, трамвай кузгалып китте. Без моның артыннан әй чабабыз, әй чабабыз. «Туктагыз, безне дә утыртыгыз инде», – дип, кычкыра-кычкыра тамаклар бетте. Трамвай бара да бара. Әллә тукталышка килеп җиттек, әллә кешеләр зур сандыклар күтәргән ялан аяклы авыл балаларын җәлләде микән, трамвай туктады. Монда да билет саталар икән. Бер апа минем янга килде дә: «Купите билет», – ди. Мин әйтәм: «Трамвай бит без билет ходит. Мне билет не нужен», – дим. Кая барсам, минем артымнан бара. Аннары: «Ну, какой спрос с чаплашки!» – диде дә, кулын селтәп, урынына барып утырды.

Хәзер күз алдына китерегез инде: шушы ике баланы язмыш театр дөньясына алып кереп китә. Ленин исемендәге университет янында басып торуыбыз истә калган. Кирәргә уйладык микән, әллә күрергә генә килдек микән? Бик матур гына киенгән бер абый килде дә: «Молодые люди, что вам здесь нужно?» – ди. Мин әйтәм: «Нам бы уни... уни...». Университет сүзен әйтә алмыйча озак азапландым. Бу аптырап карап торды да: «Ну и ну», – дип кул селтәп, китеп тә барды. Ә Нәҗибә: «Их, менә шунда укысаң иде», – ди. «Без монда керә алмабыз, әйдә, берәр институтка барып карыйк», – дим.

Урамнан барганда, Нәҗибә бер игъланны күреп туктады. «Карале, Мәскәүдә Щепкин исемендәге театр училищесы татар студиясенә студентлар кабул итә», – дип язылган. Уку биш ел. Әйдә, документларны шунда бирик, ичмаса, Мәскәүдә укырбыз», – ди. Мин: «Без бит училищега түгел, институтка керергә килдек», – дим. Бу мине ныклап үгетләргә тотынды. «Ул бит Казан түгел, Мәскәү, Мәскәү, җитмәсә биш ел укырга кирәк. Керә алсак, даны ни тора! Әйдә, барып карыйк әле», – ди.

Университет Академия театрына якын икән, тауны гына төшәсе. Түзмәдем, Нәҗибәгә ияреп киттем. Барып кердек академия театрына, тышта эссе, монда салкын, рәхәтлегеннән күңел күтәрелеп китте. Кабул итүче абый Нәҗибәнең документларын алды. «Әйбәт укыгансың икән, рәхмәт, кызым», – ди (Ул Татарстанның халык артисты Һидаят абый Солтанов булган икән). Миңа карап торды да: «Сиңа монда укырга керергә киңәш итмәс идем, буең кечкенә, үзең артык ябык, артистлар озын буйлы, матур булырга тиеш», – ди. «Абый, мин үсәм әле, миңа бит 16 гына яшь, минем абыйлар синнән дә биегрәк», – дигәч, рәхәтләнеп көлде дә, документларымны алып калды.

Менә имтихан вакыты да килеп җитте. Беренче мәртәбә шундый матур кызларны, егетләрне күреп, шаккаттым. Алар белән чагыштырганда без бөтенләй башка кешеләр идек. Чөнки авыл икәнлегебез әллә каян күренеп тора, йөзебезгә чыккан. Әмма безне театр училищесына кабул иттеләр, чөнки без «самодеятельность»ка йөреп бозылмаган икән. Табигать ничек бар, шулай сакланган, ягъни табигыйлык ярылып ята иде. Нәҗибә дә, мин дә театрның ни икәнен күз алдына да китерә алмыйбыз, чөнки татар театрын күргәнебез юк иде. Театральныйга кергәнебезне беркемгә дә әйтмәдек, әмма кешеләр безнең Мәскәүгә укырга керүебезне ишетеп өлгергән иде. Хәер, Нәҗибәнең туганнары да белгәндер, чөнки алар укымышлы иде. Авыл кешесе өчен артист булу бернинди дәрәҗәгә дә саналмый, киресенчә, «тапкан һөнәр дип, туры килгән саен: «Эй, ты артист», – дип мыскыл итәргә генә торалар иде.

Кызык бит, без 10 нчы классны бетергәндә Щепкин исемендәге театр училищесы татар академия театры өчен артистлар әзерләр дип күз алдына китерү дә мөмкин түгел, ничек шулай туры килергә мөмкин? Язмыш инде бу, валлаһи, язмыштыр! Язмыштан узмыш юк, дип тиктомалдан гына әйтмиләр шул. Бу Нәҗибәгә дә, миңа да туры килә. Институтка керә алыр идемме, анысын әйтә алмыйм, ә театр училищесына керергә Нәҗибә генә котыртты.

Ул бөтен күңелен биреп, тырышып укыды, гаҗәп инсафлы, тәртипле кыз иде. Аның бөтен теләге бары тик укуда гына булды, шуңа күрә Туфан Миңнуллин аңа игътибар иткәндер дә инде. Театрга кайткач та, Аяз абый Гыйләҗевнең «Көзге ачы җилләре»ндә Гандәлиф, Тажи Гыйззәтнең «Чаткылар»ында Маһисәрвәр, Шәриф абый Хөсәеновның «Әни килде»сендә Гөлчирә, саный китсәң, аның рольләре дистәләгән. Театрның иң талантлы актрисасы булып үсеп җитте. Нәҗибә Туфан Миңнуллинның «Миләүшәнең туган көне»ндә, «Дуслар җыелган җир»ендә, «Хушыгыз» спектакльләрендә иҗат иткән Миләүшә образын башкарды. Миңа: «Туфан Нәҗибәне үстерде, аңа атап пьесалара язды», – дип гел әйтәләр иде. Дөресен әйтергә тиешмен: әгәр Нәҗибә бар күңелен, җанын салып уйнамаса, ул спектакльләр, бәлки, андый зур уңышка ирешә алмас иде. Нәҗибәнең бу рольләрне зур югарылыкта башкаруы, Туфан өчен дә зур сөенеч булгандыр.

Аннары Нәҗибә үзе дә сизмәстән, кинәт өлкән яшьтәге хатыннарны уйный башлады: Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә» трагедиясендә Тәңкәбикә, «Ташлама утны Прометей» трагедиясендә Фемида, Рабит Батулланың «Кичер мине, әнкәй» әсәрендә Миңзифа, Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендә Өммия… – алар дистәләгән. Актрисалар өчен иң авыры карчыкларны уйный башлау, аның өчен аерым типаж кирәк. Элекке вакытта, менә бу актриса карчыкларны гына уйный ала дип, аңа башка рольләрне тәкъдим итеп тә тормаганнар. Нәҗибә исә шундый актриса: бүген комедиядә карчыкны, икенче көнне драмада хатыннарны, теләсә, трагедиядә дә уйнарга бөтен мөмкинлеге бар. Шуңа күрә режиссерлар, бигрәк тә Камал театрының баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов аңа теләсә нинди рольне ышанып тапшыра. Театрда режиссерларның сиңа артист буларак ышануы, хөрмәт итүе – үзе бәхет. Мин аның эшләре белән һәрвакыт горурлана идем. Кайвакыт, кызып киткәч: «Син Туфаннан бер дә ким түгел, синең театрда кабатланмас үз урының бар», – дип бәхәсләшә идем.

Авылдашымның талантлы актриса булуы – минем өчен дә бәхет. Әгәр бәхетсез актриса булса, нишләр идең? Миннән гел сорыйлар: «Нәҗибә ни хәлдә, рольләр уйныймы? Нигә аны үзең белән алып кайтмыйсың? Кайбер кешеләр безне, бер авылдан булгач, бергә яшиләр, дип уйлый иде, ахры. Театрда миңа «незаменимых нет» дип, теңкәмә тияләр иде. Хәзер инде аңлыйм, аны талантлы кешедән көнләшеп, сине бик үк яратып бетермәгән хуҗалар гына әйтә. Театрда Нәҗибә кебек татар милли характерын тудыра алырдай актрисалар сирәк. Әгәр Нәҗибә вафат булмаса, бу турыда язып та тормас идем. Без бит кеше бу дөньядан киткәч кенә аның бәясен аңлыйбыз.

Әле дә күз алдымда, авылыбызның зиратын яңадан эшләткәч, бер төркем театр артистлары белән Нәҗибә дә кайткан иде. Шул вакытта Нәҗибә гел елады да елады. Әллә юкка чыккан авылыбызны озак күрми торганга? Әллә бөтен авылдашларны күреп, аларга бу бәйрәмгә килгәннәре өчен рәхмәт әйтеп, барысын да кочаклап чыгасы килдеме? Ул ашкынып-сөенеп, күңелендә йөрткән уй-теләкләрен авылдашларына ачып бирергә тырышты. Минем Нәҗибәне мондый халәттә күргәнем юк иде. Кадерле кешесе Туфан турында да, әгәр исән булса бу хәлләрне күреп сөенгән булыр иде, юк бит, юк, дип өзгәләнде. Нәҗибәнең күңеле, йөрәге нәрсәнедер сизенгән, ахрысы. Шушы очрашудан соң Нәҗибә авылга кайта алмады...

Их, Нәҗибә театрда шундый рольне уйнаса, тамашачы ничек кабул итәр иде икән, дип күп тапкырлар уйландым. Драматург булсам, Нәҗибәгә багышлап шундый роль язар идем, анда ул татар халкының бөтен фаҗигасен ачып салыр иде. Кызганыч, аңа андый рольне уйнарга насыйп булмады.

Әзһәр ШАКИРОВ,
Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

Мәдәни җомга
10 март
№9, 2023

Алмаз ӘХМӘТГАЛИЕВ

БУМЕРАНГ

Чишмә буенда үскән таллар артыннан әкрен генә кояш күтәрелә. Күк йөзе зәп-зәңгәр, бер болыт әсәре дә күренми. Офыкның бер читендә кояш балкыса, икенче читендә ай карап тора. Тирә-юньдә кошлар сайрый, гөлбакчада күбәләкләр оча.

Шушы матурлыкка хозурланып, Хәсән бабай өйгә керде. Ул түр якның тәрәзәсен ачып куйды да, үзе өстәл янындагы урындыкка утырды. Ачык тәрәзәдән кергән йомшак җил аның чал башыннан сыйпап алды. Ә гөлбакчада аңкыган чәчәкләр исе, Казанда яшәгән оныгын хәтерләтеп, борын очын кытыклады, битләрен үпте.

Хәсән бабай, бераз хәл алгач, өй почмагында эленеп торган сәгатькә күтәрелеп карады. Ул дога укып алды да: «Озак тормаслар, тиздән балалар да кайтып җитәр, чәй куярга кирәк!» – диде. Ике-өч минут та үтмәде, картның чәйнеге сызгырганда, капка артында кызы белән оныгының тавышы ишетелде.

Оныгы әнисенә:

– Әни, әни, бабай миңа бумеранг ясаган микән? Ул бит теге кайтканда вәгъдә иткән иде.

Әнисе:

– Улым, ясагандыр, әгәр ясамаган булса, икегез ясарсыз, җәйнең әле тагын ике ае бар, – диде.

Хәсән бабай аларны каршы алырга чыкты. Ул, кечкенә Илшатны күреп:

– Ууу, зур улым кайткан, ярдәмчем кайткан! – дип, аны үсендереп җибәрде.

Онык:

– Саумы, Хәсән бабай! Әйе, сиңа булышырга кайттым. Көтү көтәргә кайттым.

Хәсән бабай:

– Улым, сиңа ничә яшь булды инде? Еллар узган саен, хәтерем дә начарлана.

Онык:

– Миңа алты тулды, Хәсән бабай.

Хәсән бабайны авылда иң олы, иң яхшы балта остасы, диләр. Авылда калыккан йортларның һәммәсенә аның кул көче кергән. Ул авылның малайлары арасында хәтта шундый тәртип тә бар: әгәр Хәсән бабай ясап биргән бумерангың юк икән, димәк, син әле кечкенә. Андыйларны зуррак малайлар үзләре белән уйнарга да чакырмаган.

Бу тәртип турында Илшат белсә дә, бабасының бумеранг ясамаганына һич тә күңеле төшмәде, ул бит иртәгә аның белән көтүгә чыга, чыбыркы шартлатырга өйрәнә. Ул әле үзе дә хәтерлидер чыбыркы белән ботына сукканын, ә бизәкләп куйган очы аның колагына эленеп калганын.

Узган ел Илшат, чыбыркы шартлатам диеп, сул як колагын җәрәхәтләгән иде. Аның колагы төн буе сызласа да, ул барыбер күзеннән яшь агызмады.

Иртән Илшатның әнисе күзләрен ачканда, Хәсән бабай ишегалдында нидер ясый иде. Гөлшат чәчләрен тарап үрде дә, тормыш иптәше бүләк иткән ак яулыкны бәйләп, әтисе янына чыкты.

Хәсән бабай:

– Кызым, нигә йокламыйсың?

Гөлшат:

– И, әткәй, үзең әйтә идең бит: «Иртән торсаң, ит пешә, соңга калсаң, бит пешә!»

Хәсән бабай кызы Гөлшатка елмайды:

– Бик дөрес сүзләр, кызым! Менә мин дә чыбыркыларны әзерләдем. Оныгыма бумеранг ясадым.

Гөлшат:

– Әткәй, Илшат кечкенә бит. Күршеләрнең тәрәзәсенә тидерсә?

Хәсән бабай:

– И, кызым... Мин бакыйлыкка күчсәм: «Бабай бумеранг ясамады!» – диеп, оныгым үпкәләр.

Алар икесе дә кинәт тынып калды. Аннары Хәсән бабай янә сүз башлады:

– Кызым, бүген Илшат төне буе саташты. Бер үткәнемдә көлде, ә икенчесендә елый иде.

Гөлшат:

– Нигә икән, әткәй?

Хәсән бабай:

– Бумеранг очыргандыр. Аннары, күрше Кәрим малае әйтмешли, Кылдый Фәнис рәнҗеткәндер...

Әтисе Гөлшатка сорау бирде:

– Кызым, хәтерлисеңме: бервакыт авылда тавык-чебешләр, үрдәк бәбкәләре кырылды?

Гөлшат:

– Әйе, әткәй, хәтерлим. Аны онытып буламы соң? Чупакабра шактый хуҗалыкка зыян салды.

Хәсән бабай:

– Кызым, ул Чупакабра булмаган, ә Кылдый Фәниснең эше икән.

Гөлшат:

– Әткәй, ничек инде?

Хәсән бабай:

– Кылдый Фәнис үртәк-чебешләрне тотып алган да аларның өстенә атланган. Әле ярый, күрше Кәримнең кечкенә малае күреп өлгергән. Миңа ул килеп әйтте: «Кылдый Фәнис сезнең каз бәбкәләренең һавасын пыслата», – дип.

Гөлшат:

– Һә-ә-ә-ә-ә...

Хәсән бабай:

– Ярый, кызым, көтүгә әзерләнергә кирәк. Син Илшат белән Илһам абыеңны уят. Мин авыл башына менә торам. Чыбыркы тавышын ишеткәч кузгалсыннар.

Гөлшат өйгә кергәндә, улы белән абыйсы чәй эчә иде. Ул аларга әтисенең авыл башына менеп китүен әйтте.

Илһам:

– Йә, энекәш, тукландыңмы? Безгә кузгалырга кирәк!

Илшат:

– Абый, мин күптән әзер!

Алар капка төбенә чыкканда, Хәсән бабайның чыбыркы тавышы ишетелде. Әтисенә җавап итеп, Илһам да үз чыбыркысын шартлатты. Икенче тапкыр шартлатканда, авыл халкы малкайларын урамга чыгара башлады.

Ун-унбиш минут та үтмәде, көтүче егетләр юлга кузгалды. Көтү урамнан алга барган саен, һәр хуҗалыктан өч-дүрт сыер, унлап сарык кушылды. Ә яшь таналарны хуҗалар үзләре илтеште.

Көтүчеләр авылны чыкканнан соң, иске күпер ягына борылып, яшел тауга юл тотты. Аларны алда болын чәчәкләре, яшел үләннәр, җиләк исе сәламләде...

Тау юлыннан менгәндә, Илшат артына каерылып карады. Ә анда – авыл! Шырпы кабы кадәрле йортлар, алсу офыкка таба сузылган ямьле урман. Илшат, шушы матурлыкны күзәткәндә, үзен зур киңлекләрне ялаучы бөркет сыман хис итте. Яшь көтүче як-ягына караган саен, табигать аңа үз серләрен ачты.

Бераз барганнан соң, тәшлеккә килеп җиттеләр. Кояш күкнең иң югары ноктасында иде.

Хәсән бабай тирә-якка каранып алды да уларына әйтте:

– Малкайлар берәм-берәм ята башлады, әйдә, тамак ялгап алабыз!

Илшат, Хәсән бабасының сүзләрен ишеткәч, аркасына аскан сумкадан ак җәймә алды. Ә Илһам абыйсы аны иплэп кенә җиргә җәйде дә сумкасындагы тәм-томнарны шунда тезде. Яшь көтүче абыйсының табын хәстәрләгәнен сабырсызлык белән карап торды. Ул, озак итеп күзәткәннән соң, нидәндер күңеле сүрелеп, читкә барып утырды. Илһам абыйсы аны күпме чакырып караса да, ул табын янына килмәде...

Хәсән бабай, намазын укып бетергәч, Илшатны үзе чакырып карарга булды:

– Улым, кил әле, мин сиңа бер әйбер бирәм.

Илшат үпкәләгән тавыш белән бабасына эндәште:

– Йомыркамы?

Хәсән бабай, оныгына карап:

– Юк, улым, йомырка түгел, күптәнге хыялың!..

Яшь көтүче җәйлап кына бабасы янына килде һәм болытлар артында балкып торган кояш кебек елмаеп куйды.

Хәсән бабай:

– Кил, улым, якынрак кил! Бәлки, ашыйсың да киләдер, әнкәң әзерләгән ризыкларны авыз ит.

Хәсән бабай оныгы белән иплэп сөйләшсә дә, аның сүз сөреше ризыктан өстен булмаска кирәклеген аңлатты.

Кечкенә Илшат әнисе әзерләгән ризыкларга үрелгәч кенә, ул сумкасыннан тастымалга төргән, урак айга охшаган әйбер алды.

Хәсән бабай, оныгының башыннан сыйпап:

– Улым, мин сиңа вәгъдә иткән бумерангны ясадым. Бу гади әйбер түгел, моны явыз ният белән очырсаң – явызлык, яхшы ният белән очырсаң, яхшылык кайтыр, диде.

Бу сүзләрдән соң кояш кебек балкып торган Илшатның йөзеннән тир тамчылары бәреп чыкты. Бумерангка үрелгән куллары кинәт туктап калды.

Шырпы кабынып, сүнәр вакыт үткәч, Илшат бабасының кулыннан бумерангны алды. Аның да бит, башка кечкенә малайлар кебек үк, Кылдый Фәнис янында зур булып күренәсе килде.

Ул бумерангны бер-ике тапкыр күккә очырып караганнан соң, Илһам абыйсының тавышы ишетелде:

– Көтү кузгала башлады!

Илшат:

– Бабай, мин кайсы якны саклыйм?

Хәсән бабай:

– Улым, син ерганакның теге ягына бар, анда ике сыер көтүдән качмакчы була!

Шатлыгы эченә сыймаган Илшат чыбыркысын алды да бабасы әйткән якка йөгерде. Ә үзе хыялында һаман бумеранг очырды...

Көн буе баш өстендә очып йөргән кояш Зиректауга таба якынлаша башлагач, Хәсән бабай биш тапкыр чыбыркысын шартлатты. Бу чыбыркы тавышлары кайту хәбәрен аңлатты. Хәбәрне аңлаган шикелле, малкайлар да авыл ягына борылды.

Көтүчеләр тау юлыннан төшкәндә, Илһам абзыйны чишмәдән кайтучы кызлар урап алды. Илшат янына да бер кыз бала чиләк-көянтәсен асып килгән иде.

Бу авылда шундый йола бар икән: өйләнмәгән егет кайсы кызның чиләгеннән су эчә – шул сылу, имеш, аның хатыны була. Авылның өлкән агайлары әйтүенчә, моның белән һәр буын үзенең ярату хисен белдерә.

Көтүчеләр капка төбенә кайтты. Алар йорт ишеген ачып кергәндә, борын очларын мичтә пешкән икмәк исе кытыклады.

Хәсән бабай, Гөлшатка елмаеп:

– И, кызым, рәхмәт сиңа, әниең Хатирәне искә төшердең. Көтүдән кайтканда, ул да безне шулай каршы ала иде.

Гөлшат, Хәсән бабайның сагышлы күзләренә багып:

– Әйе шул, әткәй, хәтерлим, – диде.

Хәсән бабай белән Гөлшат бер-берсенең күзләренә озак карашып торганнан соң, кечкенә Илшат әйтеп куйды: «Әни, минем ашыйсым килә!»

(Ахыры киләсе санда.)

Зиннур МАНСУРОВ

НИКАХ МӘХӘББӘТКӘ ВАЗЫЙФАЛАР ЙӨКЛИ



I

●Сөюнең гап-гади асылы парлашып чирләүдән гыйбарәт.

●Мәхәббәт – өлешләп түләү шарты белән бирелә торган сәмави һәдия.

●Спортчыга нәсыйхәт: «Яхшыдан яхшы допингны мәхәббәттә генә табарсың».

●Котмәгәндә килгән сөю башны ныграк әйләндерер.

●Җиту кыздагы сихерле сөю хисе күпләр өчен йогышлы булырга мөмкин.

●Сөюдә тупланган тәҗрибә хаталык кылудан сакламас.

●Мәхәббәт бәйнә-бәйнә аңлатырга яратмый.

●«Сөям!» диеп әйтүдә ихласлык җитеп бетми.

●Тәүге мәхәббәтегез беренчелеген бирмәс.

●Үзең кичергән мәхәббәтне саный башласаң, күктә очкан кошлар кебек, ярату хисе таркауланып китәргә мөмкин.

●Ир-ат тиңе булмаган әһлия-җефет белән гомер итсә, хыял аша тәүге мәхәббәтенә әйләнеп кайтмас иде.

●Икеләнү кортын йөртүче зат бер күрүдә гашыйк булмаячак.

●Мәхәббәт күз яшьләренә аеруча тиз ышана.

●Гашыйк утында янучы хаким җәнаплары вакытлыча дөрес карарлар чыгара алмас.

●Ярату атлы хасият һәр адәми затка ике дөньяга да җитәрлек итеп бирелә.

●Кешелек бөтен чиргә дә дәва уйлап чыгарыр, мәхәббәт газабын имләр өчен генә дару табылмас.

●Дөньяда бихисап ир-атның берничә мәртәбә өйләнеп яшәве аларда берничә хатынга җитәрлек мәхәббәт булганын аңлатмас.

●Җирдәге мәхәббәт үрнәгенең үзгәреш кичерүе яшәешне шушындый хәл-халәткә китереп җиткергән.

●Мәхәббәт акча исен яратмас.

●Ир-атка гомуми сөю оеткысы чагыштырмача мулрак күләмдә салынган.

●Оҗмахтан икәүләп сөрелгән парга җирдә дәвамлы көндәшләр табылган.

●Сөйрәлчек: «Һәртөрле чагыштырма алымнарны өйрәнү гаилә кешеләрен хыянәткә этәрә».

●Байтак кызларның мәхәббәте күкне колачлый алырлык, кайсыбер кызныкы акча янчыгына сыярлык кына.

●Тугрылык саклаган ирне Кызыл китапка кертерлек.

●Хөр яшьлектән качарга теләсәң, һәмишә кыз-кымыз артыннан чап.

●Романтика атлы кызлар берчак сездән аерылыр.

●Бөтен ир-ат халкы үзенең табигый чын йөзен бары тик хатын-кыз күзендә генә күрә ала.

●Капма-каршы җенестән булу адәм затларын тинтерәтә: ул аларны бер-берсенә тарта да, еш кына бер-берсеннән этәрә дә.

●Үзеңне генә ярату газапны күбрәк китерә.

●Хатын-кыз исемен йөртүче зәгыйфь затка җиде иргә чыдардай түземлек тупланган.

●Мантыйкый сөземтә: «Җәннәт бакчасында Адәм белән Хәваны сынау нәтиҗәләре буенча шәригать кануннарында хатын-кызга баглы тыюлар чагыштырмача күбрәк каралган».

●Гүзәл кыз серлелек кыйммәтен югалтса, аның үзенә карату куәсе дә кимер.

●Сөйгән чакта баш югалтып алу алай куркырлык зур бәла түгел.

●Әүвәлге яугирләрнең мөгезле очлам кию аларның хатыннарына бозыклык ишарәсе ясамый.

●Хатын-кыз заты сөйләшми торган чакта тагын да серлерәк булып күренә.

●Безнең хатын-кызлар сөттә генә коенгалап яшәр иде, әмма болай пакьләнергә гелән ир-ат комачаулык итә.

●Чырайга сөртелгән кызылсу иннек эчке оялу билгесен аңлатмас.

●Сылу кызый зиначы ятьмәсенә аягыннан эләгеп әрәм булыр.

●Хәстәрле бәндә үз мәхәббәтен бервакытта да биреп бетермәс.

●Хатын-кыз каршында алдашып аласың килсә, аның яшәреп китүе турында тәкрарла.

●Мәхәббәттә тугрылык күрсәтә алсаң, байтак бәладан котылып калачаксың.

II

●Бала имезүче анадан каралык эзләмәскә тырыш.

●Ана карынындагы бала да үз холкын күрсәткәләп тора.

●Һәрбер кунак кызы тыйнак булып чыкмый.

●Сөйкемле кызларны күргәч, күпләр хыялга бирелә.

●Нарколог: «Гаять ярсулы яшьлектә тәмам баш югалтып ярату әфьюнның үзгәрәк бер төрен куллану хәленә охшаш».

●Тәҗрибәсе сизелеп торган кыз күп кенә егетне шикләндерер.

●Гыйбрәтле үткәне булган кыз-кыркынның киләчәге шактый томанлы күренер.

●Күрше хатын картая белмәс.

●Хатын-кызда аяклы гүзәллек гәүдәләнгән.

●Җете матурлыгын эчкәрәк яшерә алучы кыз үз акылын эзлекле тәртиптә тирәнәйтә башлар.

●Матур булып дөньяга килүче кызларны тормышта өстәмә сынаулар көтеп тора.

●Теләсә нинди курорт романы хатын-кыз аягы белән языла.

●Тәүге мәхәббәт сине акрын-акрын сукырайтса, икенчесен кичергәндә күзең ачыла башлар.

●Даим зарар итеп торган гадәтне аналар сөте генә җиңә алмас.

●Игезәкләр: «Ана карынында алдашулар булмый».

●Үзләрен милләт анасына тиңләүче газиз затлар туган телне инкыйраз тилгәненә биреп җибәрмәс.

●Аллаһның бар тереклекне яралтуын танучы кавем тавык яисә йомырка беренчеме дип бәхәсләшмәс.

●Вундеркинд: «Атаң белән анаң акыл өйрәтмә – аларга инде тәрбия биреп булмый».

●Ана күзеннән тамачак рәнҗешле яшьләрдә туфани кодрәтләр җыелып торырга мөмкин.

●Кыз-хатынның җанын зурлап, соңра тәнен хурламыйлар.

●Агач яшен аның кәүсәсендәге боҗралар буенча, хатын-кыз яшен кулындагы балдакларга карап чамаларга мөмкин.

●Хатын-кыз чынбар яшен яшереп йөрсә, димәк, аның җиләктәй чагы әле узмаган.

●Гүзәллек бәйгеләрен оештыручы: «Жюрига кергән картлар еш кына дөрес итеп бәяли алмый, чөнки аларга инде барлык кызлар да матур булып күренә».

●Муеныңа баштук менеп атланган тәкъдирдә хатының алдына сәҗдә кылу кыенлаша.

●Аналык хисе ташып ук торган хатынга үзенең ире дә бала булып күренер.

●Кайбер кыз-хатынны егеткә тиңләү байтак ирләрнең җебегәнлегенә бәйле.

●Хатын-кызның төрле булуы өйләнгәч кенә ачыклана.

●Кайсыбер телсез хатын да еш гайбәт сатып яшәүчән.

●Ир-ат белән хатын кыз арасында аерма кичерәя барган саен, Адәм белән Хәваның безгә карата нәфрәте зураер гына.

●Канәгатьсез хатын-кызлар зарлануы: «Безнең ир-ат заты кабыргаң үзеннән яралтылса, мәсьәләне һәрвакыт кабыргасы белән куяр иде».

●Ир-ат кылган кыек гамәлдән хатын-кыз күбрәк гыйбрәт алыр.

●Анаңа охшаган хатында кимчелек таба алмассың.

●Бер-берсенең җитешмәс якларын тутыра алмаучы парлар тормыш сынавында аерылышу шаукымына тизрәк бирешүчән.

●Полигамия корбаны: «Берничә хатынга өйләнеп тору кат-кат ялгышлык итүгә бәрабәр».

●Ир белән хатын арасында чалынып киткән вак-төяк ялган һәрбер якның үзен хаклы итеп сизүеннән килә.

●Бер ирнең берничә хатын белән никах яңартуы вакытлыча өйләнмичә йөргән егетләрнең өлешенә керүгә тиң.

●Никах мәхәббәткә вазыйфалар йөкли.

●Икенче мәртәбә өйләнгән иренә беренче хатынның хушлашу теләге: «Соңгысы булмасын!»

●Никах таныклыгын саклый күр – ул мирас бүлешкәндә кирәк.

●Гамәл дәфтәре белән җентекләп танышканда хатын-кызның асылы тулырак ачылыр иде.

●Уйнашчы хатынның аерым хакка тәнен сатуы тулаем гүзәл затны бәяләү әмәлен аңлатмас.

●Муенга атланган хатын җирдән ерагаюын сизенмәс.

●Хатын-кыз салган яра гомер буе сызлаучан.

●Берәр гаскәри төркем хатын-кыздан гына торса, аның белән җитәкчелек итү кыенрак булыр.

●ЗАГСта ясалмаган искәртү: «Җирдәге насыйп гомердә кат-кат өйләнү тырмага кат-кат басуны искә төшерә».

●Матурлык белән һавалану хатын-кызны тизрәк картайтыр.

●Үзләрен генә яратучылар аерылышу хәлен аңламас.

●Кешенең җенесен үзгәртү милләтне ишәйтергә булышмас.

●Кайсыбер хатын-кызга тулаем ил дилбегәсен түгел, өйнең кухнясын да ышанып тапшырырга ярамый.

●Яңадан кавышырга чакыру: «Киселгән икмәк телемнәрен баллап торсаң, алар тиздән бер-берсенә тагы ябышыр».

●Хатын-кыз гүзәллеген саклап тотуда башлыча ир-ат җәмгате җаваплы.

● Без Татарстан вәкиллегендә, Х.Гыйльфанов (уртада, ак костюмлы) белән.

● М.Җәлил һәйкәленә чәчәк салу тантанасында татар хатын-кызлар хоры.

Урал татарлары:

Февраль уртасында чал Уралның өч каласы буенча сәяхәт кылып кайттык. Екатеринбург, Чиләбе, Магнитогорск калаларының һәркайсында берешәр көн узды, «галопом по Европе» шикеллерәк булды. Күпне күрдек, бар якны ачыкладык, дип күкрәк сугардай түгел. Гәрчә... татар чире һәрбер тарафта да бер үк төрле инде.

Екатеринбургта безне Татарстанның Урал төбәгендәге вәкаләтле вәкиле Хәйдәр Гыйльфанов каршы алды. Тумышы белән Сарман районыннан, шунда Күтәмәле урта мәктәбен тәмамлаган, сиксәненче еллардан бирле Екатеринбург каласында гомер итә. Аның урынбасары Фәвия Сафиуллина да Татарстанныкы, Арча районыннан. Рифат атлы егет мәдәни чаралар оештыру өчен җавап бирә, анысы Теләчедән.

Свердловск өлкәсендә 42 татар авылы бар, ни үкенеч, сыңарын да барып күрә алмадык. Күбесенең мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбиятын укытуны ташлаган булганнар, вәкиллек һәм өлкәдәге милли автономия тырышлыгы белән соңгы ике-өч елда атнасына ике сәгать укыту кабат кайтарылган. Халык санын алу кузгатылган саен татар авылларына яңа хәвеф яный: Екатеринбургтан 140 чакрымдагы Уфа Шигере дигән авыл мәктәбендә, әнә, башкорт телен дә укыта башлаганнар. 2000 еллар үрендә мәктәптә татар теле буенча яңа дәреслекләр булмаган, искеләрен мәгариф идарәсе урамга чыгарып ташлаткан. Ә башкортлар чик сакчысы сыман һәрчак аягүрә, алар үз китап һәм дәреслекләрен вагон-вагон итеп ташып тора. Өстәвенә, алар 1999 елда ук Ә.Әсфәндияровның «Пермь һәм Свердловск өлкәләрендәге башкорт авыллары тарихы» китабын бастырып, үзләренчә келәймә суккан инде. Моннан Башкортстанның вәкаләтле вәкиле Нәфисә Тюменцеваның да, башкорт әдипләре белән әртисләрнең дә китеп торганы юк. Мәктәптә дә Шәргыя атлы башкорт хатыны директор булып алган. Нәтиҗәдә әле кичә генә татар телен укытып йөргән Рәсимә Исемәгъзамова атлы хатын башкорт телен укытуга күчкән, үзе әйтмешли, «авылдагы татар балаларын толерант булырга өйрәтә башлаган». Урыс документларында да 1647 елда ук нигезләнгән булып искә алынган авылдагы әлеге хәлләр турында моннан 15 ел элек Фәүзия Бәйрәмова чаң кагып чыкты, Казанныкылар гына ишетмәде. Корылтайларда түрәләр өчен «без – лидерлар» дигән гел шәп рапорт кирәк, аларда татар проблемаларын күтәреп чыгучыларга мөнбәр юлы бикле...

Безнең шулай аумакай яшәгәнне Мәскәү дә тиз күрә. 2002 елгы җанисәптә генә Свердловск өлкәсендәге татарларның саны 180 меңнән дә артып киткән иде, 2010 елда шушы ук сан 150 меңнән дә аска тәгәрәде. Ә 2021 елда кичектерелә-кичектерелә «үткәрелгән» җанисәп кәгазьләрендә өлкәдәге татарлар саны 84 мең чамасы гына калды. Соңгы 30 елда Россиядән 30 миллион чамасы кеше чит илләргә чыгып качты бит, ә урысны ил тотучы һәм бөек халык итеп танытырга кирәк, моңа татар, башкорт, удмурт, мари, мордва, чуаш халкын «йоту» хисабына ирешеп кенә була. Риза түгелсезме? Ул чагында менә сезгә вагон, менә камчы, менә рәшәткәләр...

Ә асылда Свердловск өлкәсендә дә һичбер төрле санау үткәрелмәгән, бер генә авыл капкасын да волонтерлар яисә власть ияләре килеп шакымаган. Паспорт өстәлләрендәге мәгълүматлар аша гына санау уздырганда, өстәвенә, әле паспортлардан милләт турындагы аерымлыкны алып ташлатканнан соң, саннарны төп халык файдасына борып, аларны урыслаштырып чыгу үтә җайлы. Татар, башкорт, ар, мукшы, мари... телләрен укыту, моның өчен мөгаллимнәр әзерләү, дәреслекләр һәм өстәмә әдәбият бастыру өчен акча түгәсе юк. «Вак» милләтләр мәдәниятен саклау да һич кирәкми, әнә, бөтенесе дә өлкән агай көенә «Барыня»ны биесен, йә «Широка страна моя родная» дигән монафыйк җырны сузсын...

Милләтләрнең үз эчендә каршылык, низаг, бүленүләр туса, икеләтә вә өчләтә файда. Бу өлкәдә бер дә сынатмыйбыз. Әнә, шушы Свердловск өлкәсе мөселманнары гына да берьюлы 6 (!) мөфтияткә бүленеп, татар халкын адәм хуры итә. Җәмгыятьләрнең бер өлеше – Уфадагы Тәлгать хәзрәт Таҗетдинга, икенчесе Мәскәүдәге Равил хәзрәт Гайнетдингә буйсына, өченчеләре таҗик, үзбәк, казах кубызына бии. Ә мәчетләрдәге намазларга йөрүчеләр сафына күз йөгертсәң, күпчелеген татар-башкорт түгел, үзбәк, казах, таҗик вәкилләре басып алган инде. Бер мулла икенчесенә буйсынмый, һәммәсе дә мөстәкыйль вә бөек...

Ирексездән, 1917 елгы большевиклар түнтәрелешенә кадәрге Россия искә төшә. Бер уйласаң, татар муллалары ул чагында ук таркау, надан, мәнсез булган инде. Шул ук бөек Шиһаб Мәрҗани белән бөек Риза Фәхретдин дә дистәләгән надан мулланың бугазына сөяк булып утырган. Шундый надан муллаларның 30 га якыны, Шиһаб хәзрәт өстеннән шикаять язып, Уфадагы мөфти Мөхәммәдияр Солтановтан аны Казан ахуны кәнәфиеннән алып ташлауны таләп иткән. Шул 30 җаһил мулла бөек Мәрҗанинең тырнагына тормаса да, Мөхәммәдияр мөфти Шиһаб хәзрәтне, алдан үзе белән килешеп, бер елга ахун вазыйфасыннан азат итеп торырга мәҗбүр булган. Риза хәзрәтне дә, нәкъ шулай ук, казыйлыктан алырга туры килгән. Мин фәкыйрегез дин өлкәсендә шыр надан көенчә баш ватарга мәҗбүр: алтышар мөфтият төзеп, татар халкын алтыга бүлгәләгән хәзрәтләрнең указ-шәһадәтнамәләрен тартып алырга, юкка чыгарырга мөмкин түгел микәнни соң? Урысларда, әнә, бер генә кала яки өлкәдә дә христиан динен

● Татарстан вәкиллеге урнашкан Агафуров йорты.

● Сәүдәгәр Агафуровның революциягә кадәр үк төзегән йортларының икенчесе.

● Без Югары Пышма имамы А.Мөхетдинов белән.

● Свердловск өлкәсе татар мәдәни үзәгендә очрашудан бер күренеш.

Екатеринбург

алтыга бүлгәләгән, патриарх Кириллга буйсынудан чыккан сыңар гына да каратун-поп юк бит! Аларда бу өлкәдә дә корыч вертикальлек. Ә нишләп мөселманнар арасында губерна-өлкә саен аерым мөфтиләр дә, кала саен мәчет өчен, акча өчен сугыш?..

Татарстан вәкиле Хәйдәр Гыйльфанов, билгеле инде, мөфтиләрнең берсе белән дә якалашып йөрми. Аның үз кайгысы. Революциягә кадәр атаклы сәүдәгәр Агафуров йорты, соңгы 25 елда Татарстанның вәкиллек үзәге булып торган мәһабәт, шәп бинага яңарту-ремонт уздырырга кирәк. Рәхмәт, Татарстан Рәисе Р.Миңнеханов 40 миллион сум акча бүлеп биргән. Йорт өлкә карамагындагы мәдәни һәйкәл булганга, һәртөрле килешү чытырманлыкларын да ерып чыкканнар. Вәкиллек хәзер вакытлыча арендага алынган бүлмәләрдә хөкем сөрә, эшчәнлек туктатылмый. Ләкин Хәйдәр әфәнде ялгыз көе генә мөфти-муллалар каршылыгын да, эт-баш, сыер-аяк рәвешендә үткәрелгән җанисәп хилафлыгын да ерып чыга алмаячак. Татар төенен Путин чишеп бирмәс, димәк, Татарстан хөкүмәте, мөфтиятләр шурасы вә җәмәгатьчелек тарафыннан күмәк ярдәм кирәк...

Екатеринбург – 1724 елда В.Татищев тарафыннан нигезләнгән һәм Петр патшага ялагайлану йөзеннән аның немка хатыны Екатерина исеме бирелгән тарихи, зур кала. Аның үзәгендә иң тәүге булып төзелгән һәм «Храм на крови» дип аталган мәһабәт собор исән-сау көе утыра, тик бүген шәһәр халкы арасында шушы мәйданда көчләп чукындырылган, әмма кабат үзенә газиз Ислам диненә кайткан өчен, В.Татищев фәрманы буенча, генерал Соймонов күзәтүендә тере көе яндырып үтерелгән татар хатыны Кисәбикә Бәйрасованың исемен һәм бу канечкеч, аяныч хәл турында искә алучы сыңар гына кеше дә юк. («Храм на крови» атлы соборлар әле тагын Чиләбе белән Петербургта да бар, үзләре үк гасырлар буена шулай атап йөртә; ә «Татарстан» журналы тышлыгында кызгылт (шәфәкъ яктысы) төстәге болытлар астында утыручы чиркәү рәсеме басылып чыккан иде, хәтта Мәскәүдә яшәүче Никита Михалков үзенең «Бесогон» тапшыруында шундый очраклы сурәткә дә ризасызлык белдерүдән тартынып маташмады – боларда гомер буе ике төрле бизмән.)

Бистәләрен дә кушып санасаң, Екатеринбургта хәзер 2 миллион 300 мең чамасы кеше гомер итә, кала 1100 кв. километр мәйданга җәелгән. Сан ягыннан Россиянең өченче каласы бит, соңгы елларда мәһабәт, заманча йортлар әкияти гөмбәләр шикелле калкып кына тора. Түп-түгәрәк итеп күтәртелгән 54 катлы йорт гаять сокландыргыч. Әмма шуннан бер чакрымда ук һәм байтак еллар элек төзелгән 35 катлы икенче мәһабәт йорт бүген инде ташландык хәлгә килгән, ишек-тәрәзәләре җимерелеп беткән. Илнең символын хәтерләтеп торган әлеге бинаны сафка бастыру яки сүтеп ташлау гамәле хуҗаларның уена да керми. Бер үк вакытта кала үзәгендә һәм бигрәк тә ерак урамнарда Бөек Ватан сугышына кадәр үк төзелгән ике катлы, Хрущев заманында калыккан биш катлы панель йортлар санап бетергесез. Россиядә – өченче, дип күкрәк сугалар, ә түбәсен шифер белән япкан йортлар һаман «чәчәк ата». Шәһәр үзәгенең бер урынында татар сәүдәгәре Баһавиев кызыл кирпечтән салган өч катлы йорт бүген дә сокландыргыч, әллә шуңа микән аны һәр тарафтан күпкатлы биналар белән томалап бетергәннәр...

Без Татарстан вәкиллегендә, Югары Пышма бистәсендәге төрек өслүбендә төзелгән мәчеттә, Свердловск өлкәсенең мәдәни үзәгендә булырга өлгердек. Сәфәребез каһарман Җәлилнең туган көненә туры килгән иде, аның Екатеринбургтагы бюстына чәчәкләр салдык, милләттәшләр алдында чыгыш ясап алдык. Иң мөһиме: гомумсаннарын 50 меңгә киметеп куйсалар да, татарларыбыз һич бирешми, милләтебез иҗтиһады өчен көчен куя әле.

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

● Югары Пышма каласындагы мәчет.

● Екатеринбург үзәгендә революциягә кадәр үк төзелгән Баһавиев йорты.



● Екатеринбург үзәгендә төзелгән һәм ташландык хәлгә китерелгән 35 катлы бина.

Рәссам-монументалист, график, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Илнур Сиражиев 1970 елның 5 мартында Казанда туган. Казан сынлы сәнгать училищесын (1989) В.И.Суриков исемендәге дәүләт сынлы сәнгать институтын (1996), Россия сынлы сәнгать академиясенең Казандагы иҗат остаханәсе стажировкасын (2001) уңышлы тәмамлаган иҗатчы.

1999-2001 елларда Илнур Илбрус улы Россия рәссамнар берлегенең Татарстан бүлегендә җаваплы сәркатип вазыйфаларын үтәде. 2003 елдан алып – Россия Рәссамнар берлеге сафында. Ун ел «Арт Сити» иҗат студиясендә сәнгати проектлар җитәкчесе булды.

2011-2017 елларда В.И.Суриков исемендәге дәүләт сынлы сәнгать институтының Казан филиалында өлкән укытучы буларак белем бирде. 2014 елдан алып Россия Рәссамнар берлегенең Татарстандагы төбәк бүлеге карамагындагы Яшь рәссамнарның иҗат берләшмәсе рәисе эшчәнлеген дә алып барды. 2016 елда – Россия Рәссамнар берлегенең Татарстан Рәссамнар берлеге бүлеге рәисе урынбасары, ә 2017-2021 елларда исә шушы бүлек рәисе вазыйфаларын башкарды. Ул соңгы сигез-тугыз ел эчендә генә дә ике дистәгә якын шәхси күргәзмәсен ачты, Россия Рәссамнар берлегенең көмеш һәм алтын медальләре белән бүләкләнде. Хәзерге көндә И.Сиражиев Татарстан Мәдәният министрлыгының Мемориаль такталар һәм монументаль сәнгать буенча эксперт комиссиясе әгъзасы да.

«ЯШЬЛӘРЕБЕЗ

– Илнур Илбрусович, рәссамнарыбызның соңгы еллардагы гомуми отчет күргәзмәләре нинди нәтиҗәләр күрсәтте?

– Ни кызганыч, «Казан» милли-мәдәни үзәгендә үткән гомуми отчет күргәзмәсеннән соң без аларны ачардай мәйданны тиз арада тапмадык та... «Казан» милли-мәдәни үзәге ябылуы мондый эшчәнлегебезне тарайтты. Аннары Сынлы сәнгать галереябызда капиталь ремонт башланып китте.... Менә, ниһаять, 2021 елда гына «Хәзинә» милли сәнгать галереясында Татарстан Рәссамнар берлеге оешуга 80 ел тулу уңаеннан чираттагы күмәк күргәзмәбезне ача алдык. Иң шәп әсәрләрдән гыйбарәт экспозиция бар сәнгать сөючеләрнең дә күңелләренә хуш килде. Бүген исә күргәзмәләребезне Яшел Үзән, Яр Чаллы, Әлмәт картина галереяларында һәм Буа шәһәрендә генә ачабыз. Кайбер шәхси күргәзмәләребез Казандагы Ә.Мәҗитов музеенда да уза. 2022 елдагы иҗат эшчәнлегебез Идел буе Болгарында ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу темасы белән бәйле булды. Бу темага багышланган күмәк күргәзмәбез Яр Чаллы картина галереясында үтте, шулай ук М.Горький һәм Ф.Шаляпин музеенда да күргәзмә ачтык. Минем карашка, нәтиҗәләребез яхшы иде.

– Сез Россия рәссамнар берлегенең Татарстан Рәссамнар берлеге бүлеге рәисе вазыйфаларыннан 2021 елда киттегез. 2017-2021 еллардагы шушы эшчәнлегегез буенча нинди йомгаклар ясадыгыз?

– Мин гомер буе бушка эшли алмаячагымны аңладым. Чөнки балаларым, гаиләм бар. Кибетләрдә ризык арзан түгел, рәссамнар да картиналарын көн саен сатмый... Безнең бүлеккә Татарстан Мәдәният министрлыгы тарафыннан бер елга нибары 381 250 сум бүлеп бирелә. Аны гомуми һәм шәхси күргәзмәләр оештыруга, афишалар, буклетлар нәшер итүгә генә сарыф иттем, ә бит транспорт чыгымнары да зур иде. Рәис булу дәверемдә Татарстан хөкүмәте җитәкчелегенә, бүлегебез ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен, транспорт чарасы сорап үтенечләр яздым. Ләкин безгә микроавтобус бирелмәде. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге автобус белән тәэмин ителгән иде. 2017-2021 еллар эчендә без Татарстан сынлы сәнгатен, декоратив-гамәли сәнгатебезне ил күләмендә таныту өчен күп калаларда, төбәкләрдә бихисап күргәзмәләр оештырдык. Аларны Татарстан калаларыннан тыш, якын һәм ерак төбәкләрдә: Төмән, Киров, Сергеев-Посад, Әстерхан, Волгоград, Ростов-на-Дону, Кронштадт, Архангельск, Чиләбе, Магнитогорск, Уфа, Козьмодемьянск, Чабаксар, Йошкар-Ола, Элиста, Мәскәү һ.б. күп кенә шәһәрләрдә ачтык. Анда да бит милли сәнгатебезне күрергә сусаган татарлар яши. Шушы кадәр активлык күрсәткән бүлек бер транспорт чарасына, әйтик, микроавтобуска лаек түгел идеме?!

Аннары Татарстанның халык рәссамнарына (алар илле тирәсе) елына бер тапкыр илле мең сум булса да бүлеп бирүне үтенеп, мөрәҗәгать хатлары юлладым. Халык рәссамнары ул акчага үзләре өчен һөнәри кирәк-ярак сатып алырлар, остаханәләре өчен җыелган бурычларны түләрләр иде. Юк, анысын да бирмәделәр. Шул рәвешле нәтиҗәләремне ясадым.

Бүген мин Яшел Үзән музыкаль театрында баш рәссам булып эшлим. Һәм шул ук вакытта, яшьләргә белем бирү теләгемне дә читкә этәрә алмыйм, В.Г.Тимирязов исемендәге инновация университеты доценты буларак, студентлар өчен рәсем сәнгатеннән махсус курс алып барам.

– Берлек бүлегенең әлегә кадәр тормышка ашмаган тагы нинди проекты бар?

– Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган Татарстан каһарманнарын киндергә төшерү белән бәйле проектыбыз бар. Архивларда мондый батырларыбызның 10-15 процентының гына фотосурәтләре сакланган. Без аларның да, сугыштан әйләнеп кайта алганнарының да сурәтләрен, образларын бер стильдә, бер рухта язарга уйлаган идек. Бу – өч-дүрт ай эчендә башкарылып чыга торган хезмәт түгел, билгеле. Аларны ясап бетергәч, үзенчәлекле хәтер китабын да нәшер итеп булыр иде. Шушы проектыбыз тәкъдим ителде, ләкин аны тормышка ашыру өчен матди булышлык күрсәтелмәде.

– Шушы елларда картиналарыгыз һәм график әсәрләрегез дәүләт музейлары өчен сатып алынгандыр, шәт?

– Егерме картинам дәүләт музейлары тупланмаларында. Хезмәтләремнең кайберләрен Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музее фондына бүләк итеп тә бирдем әле.

Билгеле, Татарстан Мәдәният министрлыгы кайбер рәссамнарның картиналарын сатып ала. Бу – һәр ел бара торган процесс. Министрлыгыбызга барып, соңгы елларда кайсы рәссамнарның, нинди картиналарын никадәр бәягә сатып

алынуы хакындагы мәгълүматны рәсми сайтка элеп куюларын үтенгәнем дә булды. Тик әлеге үтенечемә колак салучы гына табылмады. Министрлык сайтында менә дигән онлайн-күргәзмә урнаштыруга нәрсә комачау итә икән соң?! Халкыбыз, сәнгать сөючеләр һәм республикадагы бар рәссамнарыбыз үз кылкаләмдәшләренең иң шәп әсәрләрен шул сәхифә аша карап та фикер туплый алырлар иде. Безнең бүлек дәүләт тарафыннан үткәрелә торган сатып алуларга шәхси экспозицияләрдә яисә «Зур Идел» кебек күләмле күргәзмәләрдә катнашкан әсәрләрне генә тәкъдим итә килде. Дөрес, соңгы елларда инде мондый сатып алулар өчен һәр рәссам үз үтенечен, тәкъдимен яза ала. Аннары әлеге рәсми фондка сатып алуларны дәүләт музейлары, картина галереялары гаризасы аша да башкарып чыгып була дип фикер йөрткән идек. М.Җәлил сериясенә караган хезмәтләремне Яшел Үзән, Әлмәт, Яр Чаллы

КИТЕП ЮГАЛМАСЫН ИДЕ»

картина галереяларына тәкъдим иттем, алар, үз чиратында, Татарстан Мәдәният министрлыгыннан акча сорады, тик ул акча бүлеп бирелмәде. Шуннан соң ул әсәрләремне дә әлеге картина галереяларына бүләк итеп бирдем.

– Ә менә төрле дәүләт премияләре буенча бәйгеләрдә катнашкан әсәрләрнең дәрәҗәләре нинди?

– Премияләр дигәннән, мин үзем дә лауреат. Х.Якупов исемендәге һәм Н.И.Фешин исемендәге премияләр белән бүләкләндем. Премияләр булу бик әйбәт, тик шундый бүләкләргә лаек булган кайбер иҗатчыларның хезмәт дәрәҗәсе югарымы соң?! Әйтик, бездә Н.И.Фешин исемендәге премиягә инде... наив сәнгать юнәлешендәге иҗатчы да лаек булды. Моны ничек аңларга? Татарстанның күп кенә район-калаларында искиткеч югары дәрәҗәдә иҗат итүче, гаять тәҗрибәле һәм талантлы һөнәри рәссамнарыбыз да бүләкләнгәне юк әле ул премия белән... Алар Н.И.Фешин премиясенә күптән лаек.

– Илнур Илбрусович, моннан дүрт ел элек сез Казанда Сынлы сәнгать-сәнәгать академиясен ачу нияте белән янып-көеп йөргән идегез...

– Бу ниятем сүнде, чөнки милли гореф-гадәтләребезне яңарту белән бәйле уку-укытуны җайга салу, киң колачлы белем бирүче милли академия ачу өчен Татарстанда киләчәкне күзаллый белүчеләр булуы кирәк... Күрәсез, сәләтле рәссамнарыбыз азая бара. Кызганыч, 2021 елда гына да мин 15 рәссамыбызны җирләүдә катнаштым. Яшьләребез югары уку йортларында белем алу өчен башкалага китә. Алар анда комга аккан су кебек югала, ягъни талантлылары, укып бетергәч, шул зур калаларда эшләп тә кала. Мин үзем дә башта шул юлны үттем. Бирегә әти-әнием гозерен тыңлап кына кайттым.

Милли сәнгатьне үстерүгә йөз тотарлык академия ачып, уку-укыту эшен башларга мөмкинлекләр тудырылган корпус әле дә бар. Ул «Тасма» янәшәсендә, әлеге корпус өчен җаваплы зат П.А.Егорушкин да якты максатлы уку йорты ачуга һәрчак теләктәш булды. Бу корпус реставрация институты ачар өчен махсус әзерләгән булган. Тик әлеге яңа институт шулай ук ачыла алмаган.

Академия ачылса, Урал, Себер якларында үскән яшьләребез дә тора-бара шушы уку йортына тартылыр иде, чөнки Себер ягында бер югары уку йорты гына бар һәм әле анысы да Красноярск каласында. Берникадәр вакыттан соң академия үз чыгымнарын үзе каплый башлар иде. Бездә – реставрация ясаучыларга да сизелерлек кытлык... Әмма бар гозерләремнең, мөрәҗәгатьләремнең уңай җавапсыз калуын янә сөйләп торудан ни файда?!

– Сез хәзер башкарак мохиттә хезмәт куясыз. Сез музыкаль театрдагы эшчәнлегегез белән канәгатьме?

– Бик канәгать. Театр әһелләре белән дуслыгым рәис булган чаклардан ук дәвам итә. Татарстан театр эшлеклеләре берлеге миннән М.Җәлил портретын бүләк итүемне үтенгәч, моңа да каршы килмәдем, каһарман затның бер сурәтен 2022 елда әлеге берлеккә бүләк иттем.

Шуны да онытмыйм: Мәскәүдә, институт дипломын яклаганда, диплом эшемне Зур театрның баш рәссамы да мактаган иде. Ул мине Зур театрга эшкә дә чакырды, сәхнә арты эшчәнлеген күрәсем килү теләге җиңде, анда ике ай буе стажер булдым һәм шул чакларда ук театр коллективы белән тату эшли алачагымны тойган идем.

Яшел Үзәннең музыкаль театры коллективы, аның җитәкчелеге дә тел-теш тидерерлек түгел, ихлас шәхесләр. Әлеге театрыбызда илһамланып эшлим. Тәүге күләмле хезмәтем дә бар инде – А.Волковның әкияти повесте буенча куелган «Волшебник Изумрудного города» мюзиклына сәхнә бизәлеше. Быелгы яңа мюзикл өчен кирәкле декорация, костюм эскизларын да әзерли башладык инде.

– Илнур Илбрусович, рәислек эшчәнлеге тукталгач, башка рәссамнар белән аралашуыгыз кимедеме соң?

– Һич юк. Җәй айларында республикакүләм, Бөтенроссия пленэрларында, Алабугада уза торган Заманча сәнгать буенча халыкара арт-симпозиумнарда катнашуымны дәвам итәм. Шушындый мәдәни чаралар вакытындагы әңгәмәләребез күңелемә тансык, әлеге чараларда җаным белән ял итәм.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.



Сарман районының Җәлил бистәсенең 2 нче урта мәктәбендә Сөббух Рәфыйковның тууына – 110, Гөлшат Зәйнашеваның тууына 95 ел тулуга багышланган «Әдәби туган як» республикакүләм укуларның йомгаклау туры узды.

Әдипләр исемендәге укулар

● Шагыйрә Миңзифа Әхмәтшина, «Җәлил чаткылары» әдәби берләшмәсенең иң актив иҗатчысы Рәис Кәлимуллин, галим Хатыйп Миңнегулов, шагыйрә Рухия Ахунҗанова.

Әлеге мәктәптә шушы якта туып үскән яки хезмәт куйган әдипләргә, галимнәргә багышлап фәнни бәйге үткәрү матур йолага әверелгән. Җәлил нефть һәм газ чыгару идарәсе әлеге мәктәптә Җәлилнең тууына 105 ел тулу уңаеннан аның исемендәге укулар үткәрү тәкъдиме белән чыга. Ул елны «укулар»га республиканың төрле районнарыннан 800 гә якын эш килә. Фәнни бәйге 2012 елда да уңышлы үтә. Аннары филология фәннәре докторы, Сарманда яшәп, өч ел хезмәт куйган Хатыйп ага Миңнегулов тәкъдиме белән «Шушы яктан – шушы туфрактан без» проектын эшлиләр. Укулар 2014 елда Хатыйп аганың үз юбилеена багышлана. Аннары – Рәфкать Кәрами, алдагы елда – Аяз ага Гыйләҗев, 2017 дә – Дамир абый Гарифуллин, алга таба Мәдинә апа Маликова кебек олуг әдипләребез иҗатын төп тема иткән укулар да гөрләп уза. 2021дә фәнни җыен Сарман төбәгендә туып-үскән Фәрит Яхин, Әзһәр Габиди, Хәниф Хәйруллин һәм Клара Булатовага багышлап үткәрелә.

Быел да Хатыйп ага Миңнегулов ачылыш тантанасында һәр укучы өчен фәнни бәйгедә катнашу зур вакыйгага булуын билгеләп үтте, игътибарны милләт мәсьәләләренә юнәлтергә чакырды. «Татарны, башкортны, чуашны да, башка халыкларны да милләт язмышы борчый. Ун ел эчендә бер миллион татар үз телен югалткан... Безнең балаларыбыз үз телен яхшы белсен, рус, инглиз, гарәп һ.б. телләрне дә өйрәнсен. Әмма иң беренче урында татар теле, аның кыйммәтләрен белсен», – диде ул.

Бу уңайдан 750 укучыны, 50 укытучыны берләштергән мәктәп коллективының бер гаилә булып яшәвен дә әйтергә кирәктер. «Ярты гасырдан артык тарихы булган уку йортыбызның үткәннәрен барлап, киләчәкне уйлап эшлибез», – ди мәктәп директоры Альбина Гарипова. Быел уку йорты дәресләрдән тыш тәрбия бирү юнәлеше буенча инновацион мәйданчык статусына ия булган. Директор мәктәптә татар теле укытучыларының эш нәтиҗәләре аеруча куанычлы булуы турында да сөйләде. Әйтик, рус милләтеннән булган укучы Александр Фролов татар теле буенча олимпиадаларда гел призлы урыннарны яулап килгән, хәтта Халыкара олимпиадада да җиңүче булган. Аның укытучысы – Чулпан Шәйдуллина. Шулай ук бу уку елында Ландыш Шәйдуллинаның укучысы Элина Төхбәтуллина әдәбият буенча җиңү яулаган. Мәктәп укучылары инглиз теле, тарих буенча да җиңүләргә ирешә.

Фәнни бәйгедә катнашучылар һәм кунаклар С.Рәфыйков исемендәге китапханә, Зур Нөркәй мәктәбе музее хезмәткәрләре тәкъдим иткән видеофильмнар аша язучының тормышын һәм иҗатын күз алдыннан үткәрде. Зур Нөркәй авылында дөньяга килгән бала сигез яшендә үк әтисез кала, ул әнисенең төп таянычы була. Сөббух Рәфыйков башта туган авылында, аннары Чаллы татар мәктәбендә укый, соңрак Казанда югары уку йортында хәзерләү курсларында белем ала. Аны 1932 елда Сарман район газетасына мөхәррир урынбасары итеп эшкә юллыйлар. Егет ике елдан соң янә Казанга килә, «Кызыл яшьләр» газетасы редакциясендә бүлек мөдире, Татарстан дәүләт нәшриятында редактор булып эшли. 1934-1937 елларда Казан педагогика институтының тел-әдәбият бүлегендә укый. 1931-1937 елларда «Үсү җырлары», «Соңгы талпыну», «Үсмерчак» дигән шигырь һәм хикәяләре тупланган җыентыклары дөнья күрә. Әмма иҗат рухы белән янган егетнең хыяллары 1937 елның октябрендә чәлпәрәмә килә. Көнләшүчеләр язучы өстеннән әләк җиткерәләр. Искиткеч газаплаулар, гаделсезлек эчендә еллар үтеп китә. Монда калган туганнарына да җиңел булмый. С.Рәфыйковка «халык дошманы» мөһере сугылгач, аларны төрлечә кимсетүләр, җәберләүләр башлана.

Шуларга түзә алмаган энесе Самат Сахалинга чыгып китә, апасы Банат та Үзбәкстанда сыену урыны таба. С.Рәфыйковка туган якларына кайту 20 елдан соң гына насыйп була. Аның гомеренең михнәтле чоры турында Дамир Гарифуллин «Норильлаг тоткыны» әсәрендә яза.

С.Рәфыйков Зәйдә яшәп «Социалистик Татарстан» газетасының үз хәбәрчесе, соңрак штаттан тыш хәбәрче була. Күп тә үтми, әдип халкыбызга «Беренче яз» романын тәкъдим итә. Ул 1920-1930 еллардагы татар авылында барган хәлләрне чагылдырган әсәр 60нчы еллар татар прозасының авыл темасына багышланган күренекле әсәрләреннән берсе итеп бәяләнә. Язучының «Авыл иртәсе», «Тын елга буенда» романнары да укучылар күңеленә хуш килә.

1996 елда Сөббух Рәфыйковның туган авылы Зур Нөркәйдә аерым музее ачыла. Туган якны өйрәнү музееен зуррак бинага күчергәч, аның бер өлеше Сөббух агага багышлана. Әдипнең мирасын, ядкәрләрен 1971 елда язучының вафатыннан соң алып кайтканнар. Зур Нөркәй урта мәктәбе директоры Ләйлә Шәйхразиева шул вакытта язучының өстәлендәге помидор үсентеләренә игътибар итә. Бу инде әдипнең яшәүгә өмете турында да сөйли. Зур Нөркәй музее ядкәрләрен фәнни бәйгедә катнашучыларга да күрсәтү өчен алып килгәннәр иде. Язучының шәхси өстәленә кара савыты, каләме, лампасы, куен дәфтәрләре куелган. Шкафта кием-салымын эшләпәсен күрергә мөмкин икән. Иң кадерле истәлекләрдән исә романнарының кульязмалары, хатлары, Язучылар берлеге әгъзасы таныклыгы һ.б. документлары...

Филология фәннәре кандидаты Дания Сибгатуллина-Нигъмәтҗанова әйткәнчә, күренекле татар шагыйрәсе, драматург, Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Гөлшат Зәйнашеваны да тормыш артык иркәләмәгән. Иске Теләнче авылында дөньяга килгән кызчыкка ата-ана җылысын тоеп, туганнары янәшәсендә үсәргә насыйп булмый.1930 елларда гаиләләрне «кулак» тамгасы белән Себергә сөргәндә, әти-әнисе ике яшьлек Гөлшатны ерак юлга алып чыкмыйча, Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче әтисе ягыннан туган тиешле апасы тәрбиясендә калдыра.

Гөлшат бу гаиләдә ачлы-туклы үсә. Югары Тәкермәндә – башлангыч, Хуҗәмәттә җиделлык мәктәпләрне тәмамлый. Минзәлә педагогика техникумында, Казан дәүләт педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Гөлшат Зәйнашева әдәбиятка шигырьләре, җырлары, бер пәрдәле пьесалары белән килеп кергән. «Рамай» исемле зур күләмле пьесасы халык театрлар сәхнәләрендә куелган. «Гөлшат Зәйнашеваны, барыннан да бигрәк җырлар авторы буларак беләбез. Ул – 20 ләп китап авторы. Шуларның бишесе балалар өчен язылган. Җырчы шагыйрә генә җырлап торган шигырьләр иҗат итә ала. Җырларында халык иҗаты ярылып ята», – диде Дания ханым.

● Хатыйп ага мәктәп директоры Альбина Гарипова һәм Р. Ахунҗанова белән.

● Галимә Дания Сибгатуллина-Нигъмәтҗанова Сарман районы Мортамак урта мәктәбе укучысы Азалия Газизовага диплом тапшыра.

● Сарман музее директоры Дания Кәшипова Сарман мәктәбеннән Амилия Хаҗиева белән.

Быел «укулар»ның оештыру комитеты 26 районнан 327 эш кабул иткән. Жюри тарафыннан сайлап алынган эшләр җиде секциягә бүленеп тәкъдим ителде. Аның берсендә укучылар тарафыннан С.Рәфыйков әсәрләре барланса, аларга тел үзенчәлекләренә анализ ясалды, икенчесендә Г.Зәйнашева иҗаты тикшерелде. «Минем гаиләм ядкәре» секциясе иң җанлы һәм кызыклысы булып истә калды. Сарман Бөек Ватан сугышы һәм туган якны өйрәнү музее директоры Дания Кәшипова барлык эшләрне үзе тикшерүен, күңелгә хуш килерлек эшләрнең күп булуын әйтте. Бәйгенең максаты – татар телен популярлаштыру. Шуңа да рус телендә килгән эшләр төшерелеп калдырылган. Рәсем сәнгате юнәлешендәге секциядә исә әдипләрнең берәр тезмә яки чәчмә әсәре буенча иҗат иткәннәр. Бу темага 67 эш килгән булган, 11 рәсемгә урын бирелгән. Г.Зәйнашева җырларын башкару фестивалендә 54 җыр тәкъдим ителгән, аларны музыка мәктәбе белгечләре тыңлаган. Укытучыларның фәнни эшләре бәйгесендә 102 укытучы катнашкан. Алар арасында методик эшкәртмәләр, осталык дәресләре, класстан тыш кызыклы чаралар турында да материаллар булган. Бу эшләр җыентык булып тупланып чыгачак икән.

Фәнни бәйгедә катнашучыларның барысына да дипломнар һәм истәлеккә китаплар тапшырылды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.



Дуслыкны китап ныгыта

●Галимә һәм тәрҗемәче Гөлфия Гайнуллина.

Татарстан Милли китапханәсенең конференцияләр залында танылган казах язучысы, галиме һәм драматургы Мохтар Ауэзовның татар теленә тәрҗемә ителгән китабын җәмәгать эшлеклеләре, сәнгать әһелләре, галимнәр катнашында тәкъдим итү кичәсе узды. Тугандаш халыкның классик әдибе Мохтар Ауэзовның тууына 125 еллыкка багышланган әһәмиятле кичә Казахстан тышкы эшләр министрлыгы, Казан федераль университеты, Казахстанның Казан шәһәрендәге генераль консуллыгы белән берГәләп оештырылган иде. Кичәдә иң дәрәҗәле, хөрмәтле кунак исә Мохтар Ауэзовның улы – танылган галим-культуролог, Мохтар Ауэзов фонды президенты Мурат әфәнде иде. Кичәдә катнашучыларны Казахстанның Казан шәһәрендәге генераль консулы Ерлан Искаков, Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин сәламләде.

Татар-казах халыкларын бик күптәннән мәгърифәти, мәдәни, әдәби бaгланышлар бәйли. Кичә татар һәм казах халыкларының борынгыдан килгән тыгыз элемтәләре һәм әдәби яктан тугандаш булуларын, Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы» романын искә төшерүдән башланды. Мурат Ауэзов та үз чыгышында әүвәл әнисе – татар кызы Фатыйма Габитова турында сөйләде. Гыйлемле, көчле холыклы татар кызы булган Фатыйма ханым. Мурат әфәнде аның турында «хәтта немец телен миннән дә яхшы белә иде», – диде. Фатыйма апа, Казахстанда туса да, үзен һәрвакыт Казан татары дип исәпләгән. Батыр йөрәкле ханым булган, көндәлекләр алып барган. Аның ачлык еллар хакындагы язмалары бик кызганыч әдәби әсәргә тиң. «Беркем дә аның кебек 1936-1937 еллар – репрессияләр, әләкләр чорының кырыслыгын чынбарлыктагыча сурәтләмәгән. Ул гомере буе Казанга килү турында хыялланды. Әмма бу насыйп булмады. Мин бик кечкенәдән татар мәдәнияте турында, «Шүрәле» турында ишетеп үстем, Г.Тукай шигырьләрен, татар җырларын, «Кара урман»ны, «Эзләдем бәгърем сине» кебек җырларны тыңладым. Бу татар көй-моңнары, татар мәдәнияте әнием Фатыйма Габитовага репрессияләрне кичерергә булышкан, аны язмышының хәлиткеч мизгелләрендә коткарган. Мин дә Казанга килергә бик теләдем, хыялым чынга ашты», – дип сөйләде Мурат Ауэзов.

Язучының китапка кергән өч әсәре «Үткәлдәге атыш» («Караш-Караш» – «Выстрел на перевале»), һәм «Күксирәк» («Коксерек») дигән ике повесте, «Шомлы заман» («Килы заман») хикәясенең тәрҗемәчесе – университет доценты Гөлфия Гайнуллина, әсәрләр белән эшләгәндә, якты күңелле казах халкының шанлы үткәнен күзаллап елавын да әйтеп узды, шул ук вакытта аны әдипнең газиз халкын башка милләтләр кебек үк бөек, мәгърур икәнлеген тарих аша күрсәтеп расларга омтылуына соклануын да белдерде. Шул ук вакытта тәрҗемәче-галимәнең өстәлендә эш барышында һәрвакыт Әмирхан Еники китаплары торган. «Бу юкка гына түгел. Олуг әдибебез һәрвакыт мәдәнияткә, әдәбиятка зур ихтирам белән караган, һәр сүзе мәгънәне баеткан, һәр җөмләне уйлап язган. Мин дә, Әмирхан Еники сыман, Мохтар Ауэзовның язган һәр сүзенә игътибар иттем, аның уйларына төшенергә һәм хисләрен җиткерергә тырыштым», – диде ул.

Әмирхан Еники Мохтар Ауэзов белән 1957 елда очраша. Ул бу хакта болай дип яза: «Минем белән ул татарча дип әйтерлек сөйләште, һәр сүзен мин аңлап бардым. Һәм сүзен дә ул, ни гаҗәп, турыдан-туры татар әдәбияты, татар язучыларын мактаудан башлап китте. «Тукайлар, Галимҗаннар сезнең генә түгел, безнең дә беренче мөгаллимнәребез. Безнең казахта бары татар әдәбиятында тәрбияләнеп үскән язучылар да бар», – диде ул.

●Мурат Ауэзов (сулдан икенче) һәм генераль консул Ерлан Искаков (уртада) галимнәр арасында.

Хәзерге көндә республикабызда татар-казах халыклары арасындагы мәдәни-әдәби бәйләнешләрне үз иҗат юлларында, эшчәнлекләрендә һәрвакыт яңартып яшәгән кешеләр бар. Язучы һәм тәрҗемәче Лирон ага Хәмидуллин – шундыйларның берсе. Ул казах әдәбиятыннан иң гүзәл үрнәкләрен татар теленә тәрҗемә итеп, татар язучыларының әсәрләрен казах теленә күчереп, аларны нәшер итүдә күп көч куя. Мохтар Ауэзовның Лирон ага тәрҗемә иткән бер хикәясе татар телендәге казах әдәбияты җыентыгында басылып чыккан.

Татар һәм казах халыклары арасындагы мәдәни, әдәби бaгланышларны саклауга һәм ныгытуга зур өлеш керткән филология фәннәре докторы, әдәбият белгече, профессор Хатыйп Миңнегуловка Казахстанда бик еш булырга туры килә, елына алты-җиде тапкыр барып кайткан еллары да булган, Астана, Алма-Ата шәһәрләрендәге уку йортларында татар-казах әдәбиятлары һәм аларның бәйләнеше турында лекцияләр укыган, Евразия университетында, Семей шәһәрендә узган Халыкара конференцияләрдә чыгышлар ясаган, казах әдәбияты турында татар газета-журналларында мәкаләләр бастырган. Халыкара казах академиясенең уртак проектында да катнашкан.

Галим шулай ук 1860 елларда ук Казахстанда татар уку йортлары – мәдрәсәләр булуын искә алды, аларда татарлар гына түгел, казахларның да гыйлем алуын ассызыклады. 1920-1930 елларда да Семейда татар мәктәпләре, театрлары эшләгән, газеталар нәшер ителгән. Хатыйп ага соңгы елларда милләттәшләребезнең Урта Азиядәге төрки халыкларга аң-белем өләшеп йөрүен, татарларның казах җирләренә мәгърифәт алып килүен бик кечерәйтеп сөйли башлауларын, аны искә алмаска тырышуларын да искәртеп үтте.

Мохтар Ауэзовны олуг әдип итеп «Абай» трилогиясе таныта. Бүген язучының күп әсәрләрен 30 телдә укырга мөмкин. Алар арасында татар теленә Сәрвәр Әдһәмова тәрҗемә иткәннәре дә бар. Троицкида туып үскән ханым казах тормышын яхшы белгән.

Милли китапханәдә Мохтар Ауэзовның хәзерге вакытта якынча 56 китабы һәм аның иҗатына багышланган башка бик күп төрле басмалар саклана. Мурат әфәнде исә, китапханә базасын тагын да яңа китаплар белән баетты.

Китапны тәкъдим итү чарасында шулай ук М.Ауэзов исемендәге әдәбият һәм сәнгать институтының халыкара әдәби элемтәләр бүлеге мөдире, Казахстан язучылар берлеге идарәсе әгъзасы Светлана Ананьева да чыгыш ясады.

С.КЫЯМОВА.
Автор фотолары.

Айга карама кырын

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

11 март (шимбә). ***Шәгъбән аеның 19нчы көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 23.26 сәгатьтә калка, 8.01 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 11.25 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, буйсыну, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь.

Ютәлдән дәва

Кишер яки торма согын тигез микъдарда сөт белән кушалар, көненә 6 тапкыр 1 әр аш кашыгы кабалар. 2 йомырка сарысы, 2 аш кашыгы атланмай, 2 чәй кашыгы бал, 1 чәй кашыгы бодай онын кушып, яхшылап болгаталар, көн буена әледән-әле 1 әр чәй кашыгы кабып торалар (йомырка яхшы сыйфатлы һәм яңа салынган булырга тиеш). Әстерхан чикләвеген төеп, шулкадәр үк балга кушалар, шуның 1 чәй кашыгын 100 мл җылы суда эретеп, вак йотымнар белән эчәләр. Яисә 1 аш кашыгы шалфей үләнен 1 стакан кайнар суда төнәтәләр дә, шулкадәр үк сөт кушып, җылы килеш ярты стаканын эчәләр.

12 март (якшәмбе). ***Шәгъбән аеның 20нче көне. 20 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Чаян йолдызлыгында, 0.58 сәгатьтә калка, 8.11 сәгатьтә бата. 3нче фаза. Көн озынлыгы 11.31 сәгать.***

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, буйсыну, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь.

Гайморит интектерсә

Башлы суган согы, цикламен тамыры согы, каланхоэ согы, алоэ согы, бал, Вишневский мае – барысын да 1 әр чәй кашыгы кушып, әйбәтләп болгаталар. Ике мамык кисәген шул катнашмага манып алып, борын тишекләренә тыгалар, ярты сәгатьтән соң алалар. Дәва курсы – 10-15 көн. Яисә 2 аш кашыгы хан үләне (иван-чай) яфрагын ярты литр кайнар суга салып, кайнатып чыгаралар, ярты сәгать төнәтәләр, көненә 3 тапкыр, ашарга 30 минут кала, өчтән берешәр стакан эчәләр.

13 март (дүшәмбе). ***Шәгъбән аеның 21 нче көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 2.32 сәгатьтә калка, 8.27 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 11.35 сәгать.***

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

14 март (сишәмбе). ***Шәгъбән аеның 22 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 8.51 сәгатьтә бата. 3нче фаза. Көн озынлыгы 11.40 сәгать.***

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Кан басымын җайга салу

Тигез микъдарда саз кипкәре (сушеница болотная), сукыр кычыткан, чыпчык җилеме (омела белая) үләннәрен, дуләнә чәчәген кушып, шуның 1 аш кашыгын 1 стакан кайнар суга салалар, өстен каплап, ярты сәгать төнәтәләр, сөзәләр, стакан тулганчы кайнаган су өстиләр. Көненә 3 тапкыр, ашаганнан соң, яртышар стакан эчәләр.

15 март (чәршәмбе). ***Шәгъбән аеның 23 нче көне. 23 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 3.58 сәгатьтә калка, 9.32 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 11.45 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тәвәккәл адымнар ясау хупланмый. Арып-талганчы эшләргә киңәш ителми. Дару үләннәре белән дәвалану уңай нәтиҗә бирә. Иҗат белән шөгыльләнү өчен яхшы вакыт.

16 март (пәнҗешәмбе). ***Шәгъбән аеның 24 нче көне. 24 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 5.06 сәгатьтә калка, 10.37 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 11.49 сәгать.***

Артык активлык күрсәтү хупланмый. Ялгыз калып уйлану өчен уңай вакыт. Эчке тавышка колак салу файдалы. Бизләр системасы, кан тамырлары, тире, эчәклек зәгыйфь. Күзне арытмаска кирәк.

Табигать дәвалый

Грипптан менә болай дәвалану әйбәт. 5 аш кашыгы төелгән гөлҗимеш җиләген 1 л суда кайнатып чыгаралар да, сүрән утта 10 минут пешерәләр. Яхшылап төреп, җылы урында 8-10 сәгать төнәтәләр, сөзәләр. Иртән торуга 1 стакан, аннары һәр 2-3 сәгать саен яртышар стакан эчәләр (бал, шикәр кушарга да ярый). Дәва курсы – 1 атна.

17 март (җомга). ***Шәгъбән аеның 25 нче көне. 25 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 5.50 сәгатьтә калка, 12.05 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 11.54 сәгать.***

Акыл җыю көне. Интуициягә таянырга була. Күргән төшләр рас килә. Сизү әгъзалары, баш, колак, кан тамырлары зәгыйфь. Энергияне юк-барга сарыф итәргә ярамый. Ач тору файдалы.

Бавыр тәбәсе

500 г бавыр, 3 баш суган, 100 г гөмбә, 4 пешкән бәрәңге, 100 г яшел борчак, 6 йомырка, 4 бүлем сарымсак, тәменчә тоз һәм кара борыч кирәк. Шакмаклап туралган бавырны тиз генә майда кыздыралар, шунда ук вак кына туралган суган һәм гөмбә өстәп, тагын кыздыралар. Бәрәңгене шакмаклап турыйлар, сарымсакны изәләр. Бавырны, бәрәңгене – барысын бергә кушалар, яшел борчак өстиләр, тугланган йомырка, борыч һәм тоз салып, яхшылап болгаталар һәм, формага салып, газ мичендә пешерәләр. Өстенә уылган сыр сибәргә дә була.

ИСЛАМ ҖӘМГЫЯТЕНДӘ ТОРМЫШ КАГЫЙДӘЛӘРЕ

Адәм балаларының яшәү рәвеше гомер-гомердән бер-беребезнең игътибар үзәгендә булды. Бүген без Казан шәһәре «Өметлеләр» мәчете имам-хатыйбы, Казан ислам университеты мөгаллиме, ислам фәннәре докторы Алмаз хәзрәт Сафин белән дини җәмгыятьтә яшәүнең кайбер төп кагыйдәләренә тукталдык.

– Алмаз хәзрәт, Ислам җәмгыятендә әгъза булып яшәү өчен вазыйфа һәм хокукларыбызның иң мөһим булганнарын билгеләп үтсәгез иде.

– Ислам җәмгыяте – ул Аллаһның кануннары белән яшәүче җәмгыять. Коръәндә әйтелгәнчә, ул иң хәерле җәмгыять булып тора, чөнки аның тарафдарлары башкаларны изгелеккә өнди һәм начарлыктан тыя. Аллаһ Тәгалә «Әли Гыймран» сүрәсенең 110 нчы аятендә болай диде: «Сез кешелеккә чыгарылган өммәтнең иң хәерлесе булдыгыз. Чөнки сез яхшылыкка өндисез, начарлыктан тыясыз һәм Аллаһка ышанасыз».

Мөселманның бөтен кешеләргә карата булган вазыйфаларына килсәк, шуларның беренчесе – ярдәмчел булу, кешеләргә файда китерү. Аллаһ Тәгалә «Бәкара» сүрәсенең 195 нче аятендә: «Изгелек кылыгыз. Дөреслектә, Аллаһ изгелек кылучыларны ярата», – диде.

Әгәр мөселман кеше үзенең матди мөмкинлекләрен һәм җәмгыятьтә тоткан дәрәҗәсен кулланып башкаларга файда китерсә һәм ярдәм итсә, Аллаһ Тәгалә аны ярата башлый. Бер кеше Мөхәммәд Пәйгамбәр янына килде дә: «Йә Аллаһның Илчесе! Аллаһ Тәгалә кайсы кешеләрне күбрәк ярата?», – дип сорады. Мөхәммәд Пәйгамбәр: «Аллаһ Тәгалә башкаларга файда китерүче кешене күбрәк ярата», – диде (Табәрани хәдисләр җыентыгы).

Мөселманның җәмгыять каршындагы икенче бурычы – әманәтне үтәү. Әманәт – ул өстеңә йөкләнгән вазыйфаларны җиренә җиткереп башкару. Ислам динендә әманәт бик күп нәрсәләрне үз эченә ала, шуңа күрә дә ул Коръәндә күплек санда килә. Аллаһ Тәгалә «Ниса» сүрәсенең 58 нче аятендә: «Дөреслектә, Аллаһ Тәгалә сезгә әманәтләрне үтәргә боера», – диде. Мөхәммәд Пәйгамбәр: «Әманәтне үтә һәм сиңа хыянәт иткән кешегә хыянәт итмә», – диде (Әбү Давыд хәдисләр җыентыгы).

Мөселман кеше нинди эш белән шөгыльләнсә, аңа шул эшне җиренә җиткереп башкару әманәт булып тора. Мәсәлән, табиб кешегә авыруны дөрес итеп дәвалау – әманәт. Укытучы кешегә соңармыйча мәктәпкә килү һәм яхшы итеп укыту – әманәт. Төзүче кешегә сыйфатлы итеп төзү – әманәт. Ә эти-әниләргә әманәт – балаларына яхшы тәрбия бирү.

Көннәрдән бер көнне бер өлкәнең әмире, халыкның тормышы белән кызыксыну өчен, сәяхәткә чыгып китә. Озак баргач, ул бер агач төбенә ял итәргә утыра һәм каршында бик зур сарык көтүен көтүче яшь егетне күреп ала. Ул аны туктатып: «Әй егет! Синең сарыкларың бик симез күренә. Шуның берсен миңа сат әле», – ди. Көтүче егет аңа: «Бу сарыклар минеке түгел. Әгәр дә минеке булса, берсен сиңа бүләк итеп биргән булыр идем», – ди. Өлкә әмире аңа: «Синең хуҗаң хәзер безне күрми бит. Шуңа күрә һичнәрсәдән курыкма», – ди. Көтүче егет аңа: «Әгәр дә хуҗам яныма кайткач, ул миннән юкка чыккан сарык турында сораса, мин аңа нәрсә әйтәм соң?» – ди. Өлкә әмире аңа: «Син аңа: «Ул сарыкны бүре алып китте», – дип әйт. Теге егет әмирдән бу сүзне ишеткәч аңа ачуланып: «Әгәр шулай дип әйтсәм, хуҗам миңа ышаначак, ә безне ишетеп һәм күреп торучы Раббыма Кыямәт көнендә нәрсә дип әйтермен?» – ди һәм горур кыяфәт белән китеп бара. Бу көтүче егет үз эшенә әманәт буларак карый һәм шуңа күрә хуҗасын алдаларга теләми.

Мөселманның җәмгыять каршындагы икенче бурычы – башкаларга зыян салмау, начарлык эшләмәү. Мөхәммәд Пәйгамбәр әйтте: «Мөселман ул шундый кеше, кем аның теленнән һәм кулыннан башка кешеләр зыян күрми» (Тирмизи хәдисләр җыентыгы).

Башка бер хәдистә Аллаһның Илчесе: «Изгелек кыла алмаган кеше начарлык эшләмәсен. Менә бу аның өчен сәдака биргәнгә тиң гамәл булыр», – дип әйтте (Бохари хәдисләр җыентыгы).

Коръәндә аңлатылганча, мөселман кеше үзенә карата эшләнгән начарлыкка изгелек белән җавап бирергә тиеш. Менә шул вакытта әшәкелек эшләүче кеше явызлык кылудан туктаячак. Аллаһ Тәгалә әйтте: «Начарлыкны изгелек белән туктат. Менә шул вакытта арагызда дошманлык булган кеше иң якын дустыңа әверелер» («Фуссыйләт» сүрәсе, 34 аять).

Мөселманның мөселманнарга карата бурычларына тукталсак, аларның иң мөһимнәре – алтау. Мөхәммәд Пәйгамбәр әйтте: «Бер мөселманның икенче мөселман өстендә алты хакы (бурычы) бар: әгәр син аның белән очрашсаң, сәлам бир, әгәр ул сине ярдәмгә яки кунакка чакырса, аның чакыруын кабул ит, әгәр ул синнән киңәш сораса, киңәш бир, әгәр төчкереп «әлхәмдүлилләһ – Аллаһка мактау булсын» дисә, син аңа «йәрхәмүкәллаһ – Аллаһ сиңа рәхимле булсын» дип әйт, әгәр ул авырып китсә, хәлен бел, әгәр ул вафат булса, җеназасында катнашып, соңгы юлга озат» (Мөслим хәдисләр җыентыгы).

– Дини җәмгыятьтә хөрмәтле зат булу өчен, кешенең нинди сыйфатлары өстенлекле?

– Кешеләргә файда китерергә, хакларын үтәргә һәм начарлык эшләмәскә кирәк. Ибне Гомәр исемле сәхабә әйтте: «Бер кеше Аллаһның Пәйгамбәре янына килде дә сорады: «Йә Аллаһның Илчесе! Аллаһ нинди кешеләрне һәм нинди гамәлләрне күбрәк ярата?» Мөхәммәд Пәйгамбәр: «Аллаһ Тәгалә ярата торган иң сөекле кеше ул – кешеләргә күбрәк файда китерүче кеше. Ә Аллаһ Тәгалә ярата торган иң хәерле гамәл – мөселман кешене шатландыру яки аның кайгысын җиңеләйтү яисә аның бурычын түләү яисә аны ачлыктан коткару. Минем өчен мөселман туганның хаҗәтен үтәү, Мәдинә мәчетеннән беркая чыкмыйча, Аллаһка гыйбадән кылуга карганда күпкә сөеклерәк», – дип җавап бирде (Табәрани хәдисләр җыентыгы).

Элекке заманда бер кеше: «Йә Аллаһның илчесе! Безгә яхшы кешенең кем булуы турында хәбәр ит әле», – диде. Ул аңа: «Сезнең арада иң хәерле кеше изгелек кылуы өмет ителгән һәм начарлык эшләве көтелмәгән кеше. Ә арагызда иң начар кеше изгелек кылуы өмет ителмәгән, ә әшәкелек эшләве көтелгән кеше», – диде (Тирмизи хәдисләр җыентыгы).

Җәмгыятькә файдалы гамәлләрнең кайберләре турында Мөхәммәд Пәйгамбәр үзенең хәдисләрендә аңлатты. Аллаһның Илчесе әйтте: «Кардәшеңне күргәч елмаюың – сәдака, яхшылыкка өндәү һәм начарлыктан тыю – сәдака, адашкан кешегә юл күрсәтү – сәдака, сукыр кешегә юл күрсәтеп бару – сәдака, юлдан кешеләргә комачаулаган ташны, чәнечкеле ботакны һәм сөякне кырыйга алып ташлау – сәдака. Үзеңнең чиләгеңнән кардәшеңнең чиләгенә су салу да – сәдака» (Тирмизи хәдисләр җыентыгы).

Кешеләргә ачык йөзле булу шулай ук ислам дине хуплаган гамәлләрдән санала. Бу да кешеләр каршында хөрмәт казануга сәбәп булып тора. Мөхәммәд Пәйгамбәр: «Бер изгелекне дә вак нәрсәгә санап читтә

калдырма. Хәтта кардәшеңне ачык йөз белән каршы алып булса да, изгелек кыл», – диде (Мөслим хәдисләр җыентыгы).

Мохтаҗ кешеләрне ашату һәм очрашкан вакытта беренче башлап кешеләр белән исәнләшү дә хөрмәтле зат булу өчен кирәкле сыйфатларның берсе булып тора. Бервакытны Мөхәммәд Пәйгамбәр янына бер кеше килде дә: «Йә Аллаһның Илчесе! Ислам динендә нинди гамәл иң хәерлесе?» – дип сорады. Аллаһның Илчесе аңа: «Исламда иң хәерле гамәл – кешеләрне ризык белән сыйлау һәм белгән вә белмәгән кешеләргә сәлам бирү», – диде (Бохари хәдисләр җыентыгы).

Мөхәммәд Пәйгамбәрнең Әбү Бәкер исемле сәхабәсе шушы хәдисләр белән гамәл кыла торган булган. Ул һәр көнен ахирәт һәм дөнья тормышы өчен файдалы эшләргә багышлый торган булды. Бервакытны Аллаһның Илчесе сәхабәләреннән: «Бүген кайсыгыз ураза тота?» – дип сорады. Әбү Бәкер: «Мин», – диде. Мөхәммәд Пәйгамбәр: «Бүген кайсыгыз җеназада катнашты?» – дип сорады. Әбү Бәкер: «Мин», – диде. Мөхәммәд Пәйгамбәр: «Бүген кайсыгыз мескен кешене ашатты?» – дип сорады. Әбү Бәкер: «Мин», – диде. Мөхәммәд Пәйгамбәр: «Бүген кайсыгыз авыру кешенең хәлен белде?», – дип әйтте. Әбү Бәкер: «Мин», – диде. Шуннан соң Мөхәммәд Пәйгамбәр: «Әгәр дә бер кешедә шушы сыйфатлар булса, ул җәннәткә керәчәк», – диде» (Мөслим хәдисләр җыентыгы).

Күрше белән тату яшәү һәм аңа изгелек кылу да Аллаһ Тәгалә Коръәндә әмер иткән изге гамәлләрнең берсе булып тора. Күрше хакын үтәмичә торып, башка кешеләр тарафыннан хөрмәткә лаек була алмыйсың. Мөхәммәд Пәйгамбәр әйтте: «Аллаһ каршында күршеләрнең иң хәерлесе – үзенең күршесенә яхшы мөнәсәбәттә булганы» (Тирмизи хәдисләр җыентыгы).

Кешеләр белән аралашканда күркәм холыклы булуда җәмгыятьтә хөрмәтле зат булып яшәүгә бер сәбәп. Мөхәммәд Пәйгамбәр әйтте: «Дөреслектә, сезнең иң хәерлегез күркәм холыклы булганыгыз» (Бохари хәдисләр җыентыгы). Башка бер хәдистә Аллаһның Илчесе: «Мөэминнәрнең иң камил иманлысы холкы яхшы булганы. Сезнең иң хәерлегез хатыннарына яхшы холыклы булганы», – диде (Тирмизи хәдисләр җыентыгы).

Кешеләр безне хөрмәт итсен өчен, башкаларның шәхси тормышына кысылмау да таләп ителә. Мөселман кеше үзенә кагылмаган нәрсәгә тыкшынырга тиеш түгел. Мөхәммәд Пәйгамбәр әйтте: «Мөселманның иң яхшы сыйфаты үзенә кагылмаган нәрсәләр белән кызыксынмау» (Тирмизи хәдисләр җыентыгы).

– Диндә гаделлек нигезенә салынган кануннарга итәгать итү, буйсыну, бәлки, иң әһәмиятле кагыйдәләрнең беренчеседер?

– Ислам – гаделлеккә һәм тәртипкә өндәүче дин. Шуңа күрә дә Аллаһ Тәгалә мөселманга кешеләр белән мөгамәлә кылганда гадел булырга кушты. Аллаһ Тәгалә «Маидә» сүрәсенең 8 нче аятендә: «Әй иман китергән кешеләр! Бер кешене яратмавыгыз һичкенә дә аңа карата гаделсезлеккә этәрмәсен. Гадел булыгыз, чөнки ул – тәкъвалыкка иң якын гамәл. Диндар булып, Аллаһның газабыннан сакланыгыз. Дөреслектә, Ул сез кыла торган гамәлләр турында бөтенесен белеп тора», – диде.

Мөселман кеше нинди дәүләттә яшәвенә карамастан, андагы кануннарны һәм кагыйдәләрне үтәп гомер итәргә тиеш. Мәсәлән, әгәр ул урамга чыкса, юл йөрү кагыйдәләрен үти, берәр җиргә эшкә урнашса, шуның уставына буйсына. Мөхәммәд Пәйгамбәр әйтте: «Гөнаһ эшне башкару кушылган очрактан тыш, мөселман кеше яраткан һәм яратмаган эшләрдә җитәкчене тыңларга һәм аңа буйсынырга тиеш. Әгәр аңа гөнаһлы гамәлне эшләргә кушсалар, ул вакытта әмер итүче кешене тыңларга һәм аңа буйсынырга ярамый» (Бохари хәдисләр җыентыгы).

– Ислам җәмгыятендә диние булган хәлдә дөнья мәшәкатьләрен дә оныту ярамыйдыр?..

– Коръәндә аңлатылганча, бу – дөнья гамәл кылу, тормыш итү, ә ахирәт Аллаһ каршында җавап тоту дөньясы. Мөселман кеше ике дөньяны да кайгыртырга тиеш. Аллаһ Тәгалә «Касас» сүрәсенең 77 нче аятендә: «Аллаһ Тәгалә биргән мөмкинлек белән ахирәт дөньясына омтыл һәм дөньядагы өлешеңне дә онытма», – диде. Аллаһ Тәгалә «Җомга» сүрәсенең 10 нчы аятендә мөселманнарны дөнья тормышы турында кайгыртырга өндәп: «Әгәр намаз укылса, җир өстенә таралып, Аллаһның нигъмәтләрен эзләгез», – дип әйтте. Менә шушы ике аять дөнья тормышы белән дә мәшгуль булырга өнди. Шушы аятьләр белән гамәл кылып, мөселман кеше мәктәптә һәм университетта укый, эшкә урнаша, гаилә кора, балалар үстерә, хәләл юл белән үзен һәм гаиләсен тәэмин итеп яши. Шул ук вакытта ул Аллаһ каршында булган бурычларында онытмый. Биш вакыт намазын укый, Аллаһка дога кыла, Рамазан аенда уразасын тота, телен һәм әгъзаларын гөнаһлы гамәлләрдән саклый. Эшләмичә, үзеңне һәм гаиләңне тәэмин итмичә намазлык өстендә яки мәчеттә генә утыру ислам дине күрсәткән дөрес юл түгел. Киресенчә, Мөхәммәд Пәйгамбәр дә мөселманнарны эшләргә, дөнья тормышын алып барырга өндәде. Бер хәдисендә ул: «Беркем дә үз кулы белән эшләп ашаган ризыкка караганда хәерлерәк башка ризык ашамады. Дөреслектә, Аллаһның Пәйгамбәре Давыт та үз кулы белән эшләп ашый иде» (Бохари хәдисләр җыентыгы).

Икенче тугры хәлифә Гомәр ибн әл-Хаттаб мөселманнарны эшләргә әмер итеп: «Берегез дә ризык эзләүдән туктап, «Аллаһ мине ризыкландыра» дип мәчеттә эшләмичә утырмасын. Чөнки сез күктән алтын һәм көмеш ямавын бик яхшы беләсез», – диде. Мөселман кеше эшчән һәм тырыш булырга, үз көнен үзе күреп, гаиләсен тәэмин итеп яшәргә тиеш. Эшли алучы сау-сәламәт мөселманга хәер сорашып йөрү рөхсәт ителми. Мөхәммәд Пәйгамбәр әйтте: «Кем дә кем акчасы була торып та, хәер сорашып йөрсә, Кыямәт көнендә бите сыдырылган хәлдә килер» (Әхмәд хәдисләр җыентыгы). Башка бер хәдистә Аллаһның Илчесе: «Кем дә кем байлыгын арттыру өчен кешеләрдән хәер сорашып йөрсә, ул үзенә җәһәннәм күмере сораган була», – диде (Мөслим хәдисләр җыентыгы).

Әңгәмәдәш –
Рамазан КӘБИРОВ.

КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

10 март – Татарстанның халык артисты Ринат Таҗетдиновның иҗат кичәсе.
11 март – «Тормышмы бу?..» (Г.Исхакый).
12 март – 12.00 – «Килмешәк» (С.Гаффарова). 18.00 – «Өйләнәм.tat» (И.Зәйниев).
14 март – «Җәйнең бер көнендә» (Й.Фоссе).
16 март – «Гөргөри кияүләре» (Т.Миңнуллин).
17 март – «Санаулы кичләр» (А.Володин).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

11, 12 март – «Дон Кихот» (Л.Минкус).
14, 15 март – «Эсмеральда» (Ц.Пуни, Р.Дриго).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

10 март – 12.00 – «Татар теле – сәхнә теле» спектакль-дәрес (Ш.Фәрхетдинов). 18.30 – «Ашина» (Р.Зәйдулла).
11 март – «Эх, алмагачлары!» (Ш.Фәрхетдинов).
15 март – Премьера. «Аферист».
16 март – «Хыялый» (С.Әбүзәров).
17 март – «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

10 март – «Тимур һәм комета» (П.Коротыч).
11 март – 13.00 – «Минем бәхетле көнем» (Е.Гороховская), 18.00 – «Яратып туялмадым» (А.Әхмәтгалиева).
12 март – «Матур City» (А.Әхмәтгалиева).
14 март – 13.00 – «Асылкош җыры» (Р.Мөхәммәтшин). 18.30 – «Ләйлә вә Мәҗнүн» (Н.Ганҗәви, Ю.Тупикина инсценировкасы).
15 март – «Артист» (Р.Зәйдулла).
16 март – «Ромео һәм Джульетта» (У.Шекспир).
17 март – «Алтынч[ае]ч» (Л.Янсуар, Р.Гарипова).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

10 март –11.00 – «Аладдин» (гарәп әкиятләренә нигезләнгән). 19.00 – «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).
11 март – Зур залда – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әсәренә нигезләнеп куелган). Кече залда – «Мактанчык этәч» (Аманулла).
12 март – Фойеда – «Не хочу, не буду» (П.Геннадьева). Зур залда – «Теремок» (С.Маршак).
14 март – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар).
16 март – «Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин әсәре, Л.Кожевников инсценировкасы).
17 март – 11.00 – «Сказка о царе Салтане» (А.Пушкин әсәре, Л.Кожевников инсценировкасы). 19.00 – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

12 март – Җырчы Гөлнара Байназарова концерты.
14 март – «Женихи» комедиясе.
15 март – Танылган театр һәм кино артисты Ф.Раневскаяның иҗатына багышланган кичә.
16 март – Җырчы Иосиф Кабзон җырларыннан кичә.
17 март – Джаз концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

11 март – Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестрына органда Евгения Кривицкая кушылып уйный. Дирижер – Джереми Уолкер.
12 март – Наталья Железныхның ансамбле башкаруында танылган мультфильмнардан музыкаль әсәрләр яңгыраячак.
13, 17 март – La Primavera оркестрының борынгы музыка уен коралларына багышланган кичәсе. Тамашачылар виола да гамбе, кылкубыз, гиджак һ.б. музыка уен кораллары аһәңнәрен ишетә алыр.
15 март – Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестрына органда Алексей Шмитов кушылып уйный. Дирижер – Антон Шабуров.

Хәерчеләр ризыгы

Сөмбаш хәзер иң затлы сөләйман балыкларыннан санала. Бәясе дә бик кыйммәт. Шунлыктан без аны кибет киштәләрендә генә күреп, кызыгып китәбез, сатып алырга хәлебездән килми. Ә моннан берничә йөз ел элек сөмбаш шулкадәр күп тотыла торган булган, Англиядә ул хәтта хәерчеләр һәм этләр ризыгы саналган. Эшкә урнашканда, ялчылар хуҗа белән килешү төзегән: әгәр балыкны сөйләшкәннән күбрәк бирсәләр, ялчылар баш күтәргән. XIX гасырга кадәр шулай дәвам иткән. Аннан соң исә сөмбашны ерткычларча тоту аның бөтенләй диярлек юкка чыгуына китерә язган. Экологларның чаң сугуы гына затлы балыкны кабат табынга менгезгән, тик бу юлы инде – фәкать байлар табынына гына.

(“Лента.ру”).

Шөкер ит!

Бөтен пропорцияләрне саклап, кешелек дөньясын йөз кеше яши торган авыл дип күзалласаң, уйландыра торган саннар килеп чыга икән. Йөз кешенең илле җидесе – Азиядә, егерме бере – Европада, ундүрте – Америкада, сигезе генә Африкада яшәр, илле икесе – хатын-кыз, кырык сигезе – ир-ат булыр иде. Шулардан утызы – ак тәнле, җитмеше – ак тәнле түгел, утызы – христиан, җитмеше башка диннәрдә булып чыгар иде. Алты кеше дөньядагы бөтен байлыкның 59 процентына хуҗа булып, алар барысы да АКШта яшәр иде. Сиксән кеше хәерчелектә җәфаланыр, утыз өчесенең эчәргә чиста суы булмас, җитмеше укый-яза белмәс, иллесе ачлыктан интегер иде. Минут саен бер кеше туып, бер кеше бакыйлыкка күчәр иде. Йөз кешенең нибары берсендә компьютер, нибары берсе югары белемле булыр иде. Хәзер уйлан: бүген сәламәт булып йокыдан уяндың икән, димәк, син икенче атнага кадәр генә яшәячәк 1 миллион кешегә караганда бәхетлерәк. Әгәр син беркайчан да сугышта булмадың, төрмәдә утырмадың, ачлыктан интекмәдең икән, син бу дөньядагы 500 миллион кешедән бәхетлерәк. Әгәр син бүген курыкмыйча мәчеткә, чиркәүгә яки синагога бара аласың икән, син 3 миллиард кешедән бәхетлерәк. Әгәр синең яшәр урының, ашар ризыгың, кияргә киемең, йокларга урын-җирең бар икән, димәк, син бу җиһандагы халыкның 75 процентыннан бәхетлерәк. Әгәр синең янчыгыңда һәм банкта бераз акчаң бар икән, син бу дөньядагы 8 процент бай кеше исәбенә керәсең. Тормыштан зарланырга җыенгансың икән, шуларны исеңә төшер дә, шөкер ит.

(“Der Spiegel”).

Беркайчан да соң түгел

Кытайдан 86 яшьлек Ван Дэшуньның модель карьерасы очраклы башланган. Өлкән яшьтәге бу ирнең фотосурәте Кытайдагы мода атнасына әзерләнүче кием

дизайнерының күзенә чалына. Ванның яшьләр кызыгырлык мускулларын күргәч, ул аңа мода күрсәтүдә катнашырга һәм финалда күлмәксез чыгарга тәкъдим итә. Ир-ат бик теләп ризалаша. Ван 1936 елда Кытайның төньяк-көнчыгышында туган, 14 яше тулгач, трамвайга кондуктор булып эшкә урнашкан. Хәрби заводта эшләгән, буш вакытында үзешчән сәнгатьтә катнашкан, кинода берничә роль башкарган. 44 яшендә инглизчә өйрәнгән, 49 яшендә Пекинга күчеп килеп, пантомима сәнгатен үзләштергән. 50 яшендә фитнес-залда шөгыльләнә башлаган, 65 яшендә атка атланып йөрергә, 78 тулгач, мотоцикл йөртергә өйрәнгән. 79 яшендә подиумга чыкканнан соң, Ван Дэшунь Кытайда гына түгел, бөтен дөньяда танылган, аның социаль челтәрләрдәге фотосурәтләрен 2 миллион кеше караган, матди хәле дә шактый яхшырган. 2017 елда Reebok бренды илчесе итеп сайланган. Аның төп девизы – максат куярга һәм һичшиксез шуңа ирешергә кирәк, бары шул чакта гына үзеңне бәхетле тоеп була. 2021 елның августында исә Ван үзенең тагын бер хыялын тормышка ашырган – Миюн Мудзиаю аэропортында көне-төне өч ай укып, барлык сынауларны уңышлы үткән, пилот лицензиясе алган һәм зәңгәр күкне гизә башлаган.

(“Die Presse”).

Ашар өчен яшәмә, яшәр өчен аша

Япония мәктәпләрендә балаларны ашату безнең илдәгедән шактый аерыла. Бездәге мәктәп ашханәләрендә кайвакыт ризыкның иттәнме, әллә балыктанмы әзерләнгән икәнен дә аерып булмаса, Японияда туклану – белем бирүнең мөһим бер өлеше ул. Балалар аңына кечкенәдән үк сеңдерелә: алар ашаган бөтен ризык тәннәренә генә түгел, хәл-әхвәлгә һәм фикерләвенә дә тәэсир итә. “Хөкүмәт мондый карашта тора: мәктәптә туклану ул тәнәфес вакытында ял итеп тамак ялгау гына түгел, бәлки мәгарифнең мәҗбүри бер өлеше дә”, – ди дәүләтнең укучылар сәламәтлеген саклау департаменты вәкиле Масахиро Оджи. Мәктәптә төшке аш вакыты изге диярлек – беркемне дә ашыктырмыйлар, балалар тәмләп, рәхәтләнеп сыйлана. Мөстәкыйльлек тә тәрбияләүләр: укучылар ризыкны үзләре салып ала, аннан соң өстәлләрен үзләре җыештыра. Әгәр ата-ана көненә ике доллар ярым түли алмый икән, балаларга бушлай яки арзанлырак туклану программалары тәкъдим ителә. Нәтиҗәдә япон балалары, сәламәт булып үсү өстенә, үзләре ашый торган ризыкка җаваплы карарга да өйрәнә. Бәлки шуңа күрәдер дә, Япониядә уртача гомер озынлыгы дөньяда иң югарылардан берсе, ә симезләр саны аз бит.

(“Интересно.cc”).

● **Дөге – японнарның төп ризыгы.**

● **Төшке аш: какланган балык, мисо-аш, дөге, кыздырылган ит һәм брокколи кәбестәсе, сөт.**

● **Дөгеле карри, сөт, җиләк-җимеш салаты.**

